Туган телем - иркә гөлем, киңдер сиңа күңел түрем...

# Күмәк көч

ГОМУМИ РАЙОН
ТАТАР ГАЗЕТАСЫ
1930 елдан чыга.
Бәясе ирекле
№ 16 (10708)
Чәршәмбе,
19 апрель 2017 ел.
(Атнага бер тапкыр чыга)

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: 1. УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ ХӨКҮМӘТЕ (432017, Ульяновск шәһәре, Ленин мәйданы, 1). 2. "ИСКЕ КУЛАТКЫ РАЙОНЫ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРЛӘШМӘСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ (433940, УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ, ИСКЕ КУЛАТКЫ ЭШЧЕЛӘР БИСТӘСЕ, ПИОНЕРСКАЯ УРАМЫ, 30)

## Татар хатын-кызлары форумында



13 – 15 апрель көннәрендә Казанда V Бөтендөнья татар хатын-кызлары җыены эшләде. Җыенда Россиянең 60 тан артык төбәгеннән, 18 чит илдән, Татарстанның барлык районнарыннан 400 ләп, шул исәптән безнең районыбыздан да 8 делегат катнашты. Хатын-кызлар җыены Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты "Ак калфак" татар хатын-кызлары оешмасы белән берлектә уздырылды. Форум программасы кысаларында делегатлар Татарстанның Арча, Биектау, Балтач, Яшел Үзән районнарында булдылар һәм район җирлекләрендә "Ак калфак" татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмаларының эшчәнлеге, халыкның яшәеше, тормыш-көнкүреше, "Бишек туе"ның үткәрү тәртибе белән таныштылар. Казан ратушасының Колонналар залында "Калфак туе" дип аталган чара оештырылды. Ул быел татар милли киемнәрен тәкъдим итүче дизайнерлар бәйгесе буларак уздырылды.

***Зөлфия МИНГАЛИШЕВА. Иске Яндука авылы:*** Татар хатын-кызлар форумында мин быел икенче мәртәбә катнаштым һәм онытылмаслык хисләр алып кайттым. Безгә ана телебезне, мәдәниятебезне, сәнгатебезне, гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны, динебезне саклап калу һәм үстерү өчен тагын да ныграк берләшергә кирәк. Иң элек эшне үз гаиләләребездән башларга, балаларың, оныкларың белән бары татарча гына сөйләшергә, татар газеталарын, журналларын өйләребезгә яздырып укырга кирәк. “ТНВ-Татарстан”, “Планета” татар телеканаллары да безнең беренче ярдәмчеләребез булып тора. Шундый мөһим җыеннарда һәрдаим катнашуны оештыручы, районыбыз өчен, милләте өчен янып яшәүче районыбыз Башлыгы Э. Ә. Ганеевка, район администрациясе Башлыгының кеше потенциалын үстерү буенча беренче урынбасары В. А. Деникаевага һәм урындагы татар милли – мәдәни автономиясе рәисе Н. М. Рамазановага барлык делегатларыбыз исеменнән олы рәхмәт сүзләребезне җиткерәм. Киләчәктә дә шундый файдалы җыеннарда, форумнарда, очрашуларда күбрәк райондашларыбызның катнашуын теләп калыр идем.

***Лилия КАДЫРОВА. Иске Кулаткы.*** Иң беренчедән, әлеге форумда катнашуыбызны оештыручы җитәкчеләргә зур рәхмәт сүзләремне җиткерәсем килә. Казан шәһәренә булган һәр сәфәрем күңелемдә матур тәэсирләр генә калдыра. Форумда без Россиянең төрле төбәкләреннән килгән татарлар белән таныштык, шәһәр буйлап экскурсиядә йөрдек, театрга бардык, Татарстан авылларының тормышлары белән таныштык. Концерт программасында яңгыраган бишек җырлары, фольклор төркемнәренең чыгышлары, Нурия Зарипова һәм Рәмзия Ташабаеваның дизайнер коллекцияләре белән танышу да минем өчен онытылмаслык тамашага әверелде.

**21 -22 апрель көннәрендә безнең районыбызда татар милли масса-күләм мәгълүмат чараларының беренче регионара фестивале үтәчәк. “Гореф - гадәтләребезне, милли мәдәниятебезне, туган телебезне саклап калуда һәм үстерүдә татар масса-күләм мәгълүмат чараларының роле” темасына багышланган фестивальдә Татарстан, Мордовия, Чувашия республикаларында, Ульяновск, Самара өлкәләрендә чыгып килүче татар басмаларының вәкилләре катнашачак.**



## Төзекләндерү айлыгы бара

Апрельдә Ульяновск өлкәсе Губернаторы С. И. Морозовның боерыгы буенча регионыбызда төзекләндерү айлыгы игълан ителде. 14 апрель көнне районыбызның барлык хезмәт коллективлары, мәктәп укучылары өлкә шимбәсендә катнашты. Бу җаваплы чарада Иске Кулаткы эшчеләр поселогында, авыл поселениеләрендә коры урыннар чүп - чарлардан чистартылды, корыган агачлар киселде. Төзекләндерү айлыгы кысаларында районыбызда һәр атнаның чәршәмбе (среда) һәм пәнҗешәмбе (четверг) көннәрендә өмәләр оештырылачак. Үзебез яшәгән урыннарны бергәләп чистартырга, төзекләндерергә, яшелләндерергә ашыгыйк!



**21 апрель - Җирле үзидарә хезмәткәрләре көне**

**Хөрмәтле җирле үзидарә хезмәткәрләре һәм әлеге тармакта хезмәт иткән ветераннар!**

Бу – җирле үзидарә институтының ролен һәм әһәмиятен күтәрүдә, демократия һәм гражданлык җәмгыятен үстерүдә җитди адым. Бүген җирле үзидарә – халыкка иң якын булган хакимият структурасы, һәм аның халык белән дөрес мөнәсәбәте тулаем җәмгыятькә дә уңай йогынты ясый. Муниципаль хезмәткәрләр шәхси кешелек сыйфатларыннан тыш психолог та, юрист та, педагог та булырга, халык ышанычын яулап, аларны муниципаль программаларны һәм проектларны тормышка ашыруда берләштерә белергә тиешләр. Һәммәгезгә исәнлек, халык мәнфәгатенә хезмәттә уңышлар телибез.

**Э.Ә. ГАНЕЕВ,**
**Иске Кулаткы районы Башлыгы, “Бердәм Россия” партиясенең урындагы политсовет Секретаре.**
**И.А. АБЛЯЗОВ,**
**Иске Кулаткы районы администрациясе Башлыгы.**

## Талантлы яшьләребез үзләрен танытты



Күптән түгел генә Ульяновск шәһәренең халык мәдәни үзәгендә “Сембер җыры-2017” XVIIIнче өлкә фестиваль-конкурсы оештырылды. Әлеге фестиваль матур традиция буларак,1995 елдан башлап үтеп килә. Биредә Ульяновск шәһәреннән һәм барлык муниципаль берәмлекләрдән18 яшьтән 35 яшькә кадәрге сәләтле җырчылар катнашты. Конкурс өлкә буенча яшәүче талантлы милләттәшләребезне эзләп табып, аларның сәләтләрен халыкка күрсәтеп, яңа өметләр уятырга мөмкинлек ачты. Әлеге фестиваль өч номинация буенча: аерым җырлау, вокаль ансамбль, төрле музыкаль коралларда башкару иде. Катнашучылар күренекле композиторларның әсәрләрен һәм халык җырларын башкардылар. Әйтергә кирәк, һәрбер конкурсант үзенчәлекле чыгыш ясап, җиңүгә лаеклы иде.

Безнең төбәгебезнең данын район мәдәният хезмәткәрләре Фәнис Абдуллин һәм Резеда Абәйдуллина якладылар. Алар югары дәрәҗәдә үзләрен тәкъдим итеп, жюри әгъзаларын искиткеч моңлы тавышлары, матур башкарулары, үзләрен сәхнә йолдызларыча тота белүләре белән таң калдырдылар.

“Ялгыз җырлау” номинациясендә Фәнис Абдуллин - беренче дәрәҗәле, ә инде Резеда Абәйдуллина өченче дәрәҗәле лауреатлар исемнәренә лаеклы булдылар.

Барлык катнашучылар Почетлы грамоталар һәм кыйммәтле бүләкләр белән билгеләнделәр. Ә инде лауреатларга әлеге конкурсның истәлеге буларак, махсус кубоклар тапшырылды.

Без дә Фәнис белән Резеданы зур уңышлары белән котлыйбыз, аларга киләчәктә



иҗади үсешләр теләп калабыз.

Мондый әһәмиятле конкурс татар телебезне, гореф-гадәтләребезне, мәдәни-мирасыбызны саклап калу өчен бик кирәк. Дус, бердәм булып кына, без милләтебезне саклап кала алабыз!

**Әлфия ЯФАРОВА.**

**Бөек Җиңүнең 72 еллыгын каршы алуга 20 көн калды. Сугышның 1398 көне.**



**21 апрель көнне 19 сәгатьтә район мәдәният йортында**

**Җирле үзидарә органнары көне уңаеннан, “Туган ягым –мәхәббәтем минем” район фестивале кысаларында Иске Кулаткы район администрациясе коллективының бик күңелле концерты үтәчәк. Программада: элеккеге хезмәткәрләрне бүләкләү, тәбрикләүләр, музыкаль чыгышлар. Билет бәясе - 50 сум.**

| ПӘНҖЕШӘМБЕ (20.04.) | ҖОМГА (21.04.) | ШИМБӘ (22.04.) | ЯКШӘМБЕ (23.04.) | ДҮШӘМБЕ (24.04.) | СИШӘМБЕ (25.04.) | ЧӘРШӘМБЕ (26.04.) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| + 1 | + 3 | + 6 | + 9 | + 9 | + 11 | + 12 |
| - 3 | - 4 | + 1 | + 3 | + 3 | + 2 | + 6 |

КҮМӘК КӨЧ
№ 16, 19 апрель 2017 ел.

Россия Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү үзәге лабораториясе мөдире Людмила Паршина "Российская газета"га бу атнада Россия төбәкләренең күбесендә яз килсә дә, әле кызу көннәр көтәргә иртәрәк булуын җиткергән. Идел буе төбәкләрендә чагыштырмача җылы +6…+12 градус булачак. Урыны белән Иделнең сул ягында һәм Урта Иделдә +17 градус җылылык көтелә. Дөрес, яңгыр һәм юеш кар яву сәбәпле, җылылык бик сизелмәскә дә мөмкин, дип фаразлый синоптиклар.

## ЯҢАЛЫКЛАР



Президент Владимир Путин Россия түрәләрен саран булмаска, кабинетларда качмаска һәм халык башлангычларына теләктәшлек итәргә өндәде. Бу хакта ул Россия Федерациясе Федераль Җыенына еллык юлламада әйтте.

Путин шулай ук түрәләр халык белән сөйләшүдән курыкмаска тиеш, дип билгеләп үтте. Россия халкына хас булган мәрхәмәтлелек турында әйткәндә: "Безнең чорның үзенчәлекле билгесе – хәйриячелеккә киң катлам җәмәгатьчелекне җәлеп итү. Кайвакыт аз керемле кеше ярдәмгә мохтаҗ кешегә булышуына гаҗәпләнәсең. Мин сездән саран булмавыгызны сорыйм. Әйдәгез, бергәләп бу мәсьәләне хәл итик", - диде Президент.

● ● ●

Бердәм Россия" партиясе ил үсеше өчен җаваплы. Бу хакта РФ Президенты Владимир Путин Федераль Җыенга еллык юлламасын игълан иткән вакытта белдерде.

Президент сүзләренчә, "Бердәм Россия" Думада конституцион күпчелеккә ия, Хөкүмәттә дә аның вәкилләре иң күбе. Гражданнар сайлауларның нәтиҗәсен билгеләде, ил үсеше юлын сайлады. Шуңа да, Путин сүзләренчә, россиялеләрнең ышанычын акларга кирәк.

● ● ●

Мәгариф һәм фән министрлыгы балаларның ялын, сәламәтләнүен, гомумән алганда, аларның тормыш һәм сәламәтлек куркынычсызлыгын контрольдә тотачак. Бу хактагы карар Россия Хөкүмәтендә имзаланды, дип яза "Российская газета".



Ульяновск өлкәсе Губернаторы С. И. Морозовның инициативасы белән регионыбызда "Яхшы эшләр" атналыгына старт бирелде. Шушы атналык кысаларында районыбызда аз мөлкәтле гражданнарга ярдәм итү йөзеннән "Йөрәк белән дөнья буйлап", "Йөрәктән йөрәккә", "Үз агачыңны утырт" хәйрия акцияләре, Урам бәйрәме, Иске Кулаткы район больницасында авыруларга концерт программасы, зиратларны һәм елга ярларын төзекләндерү буенча өмәләр оештыру, мәктәпләрдә "Яхшы эшләр" һәм "Экология" дәресләрен, "Ял көне" клубын, Иске Кулаткы инвалидларны реабилитацияләү үзәгендә "Ачык ишекләр" көнен үткәрү чаралары каралган.

● ● ●

Ульяновск өлкәсендә мөгезле эре терлекнең саны артуы күзәтелә. Регионның авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә азык-төлек иминлеге Доктринасының төп юнәлешләрен үтәү буенча актив эш алып барыла. Күптән түгел генә Губернатор С.И. Морозов җитәкчелегендә профильле Советның утырышы үтте.

● ● ●

Ульяновск өлкәсендә "Юнармия" хәрби-патриотик иҗтимагый хәрәкәтенең яңа әгъзалары тантаналы рәвештә ант бирделәр. Регион Башлыгы С.И. Морозов әлеге хәрәкәтнең яңа катнашучыларын тәбрик итте һәм сайлаган дүрт делегат-юнармеецка II нче Бөтенроссия слетына юлламалар тапшырды. Әлеге чара 27-28 май көннәрендә Мәскәүдә булачак.

Официальная информация

# ДОКЛАД

**Главы администрации муниципального образования «Старокулаткинский район» И.А. Аблязова.
О работе по исполнению Наказов и предложений от избирателей по вопросам экономического и социального развития, удовлетворения материальных и духовных потребностей жителей района. План работы на II квартал 2017 года.**



2016 год был для нас богатым и насыщенным на самые разные события, и всё же я бы отметил самое, на мой взгляд, важное - это работа по созданию благоприятных условий жизни для жителей нашего района. Сейчас главный ресурс развития - это человеческий потенциал. Повышение качества жизни населения - основная задача в работе муниципалитета. Благодаря совместной работе администрации и населения территория района становится более благоустроенной. В 2016г. нам удалось реализовать многие проекты по благоустройству района: установлено 11 детских площадок, 2 спортивные площадки, 22 скамейки, высажено 3037 деревьев, 270 кустарников; установлен въездной знак в с.Новые Зимницы. На внебюджетные финансовые средства по акции «Подарок малой Родине» обустроен пешеходный мост в с. Новый Мостяк.

В 2016г. выполнены в полном объеме наказы избирателей Губернатора Ульяновской области С.И. Морозова, за счет средств областного бюджета проведён капитальный ремонт ФАПа с.Усть Кулатка, принята на работу заведующая ФАП –медсестра.

В январе были утверждены новые наказы и предложения избирателей на 2017 и последующие годы. Составлена дорожная карта по их исполнению. Подписан меморандум.

Основной задачей в сфере обеспечения населения комфортной средой проживания остается газификация.

Всего в районе 21 сел из них газифицировано 10. До конца 2020г. необходимо полностью завершить газификацию населенных пунктов, так как одним из важнейших условий сохранения и возврата трудоспособного населения в село является создание комфортных условий для проживания, и в первую очередь газификация населенных пунктов.

В 2016г. активно велись работы по газификации с. Новое Зеленое, завершение строительства планируется до конца 2017г.

По программе синхронизации ведется строительство межпоселкового газопровода Старая Кулатка – Верхняя Терешка протяженностью 35,68 км. На сегодня прокопано и уложено 23 км.

В 2016году во всех селах муниципального образования «Старокулаткинское городское поселение», согласно энергосервисного контракта, были проведены работы по замене уличных ламп на энергосберегающие светильники.

В целях оптимизации расходов, в марте 2017г. в р.п. Старая Кулатка установлено 71 энергосберегающих светильников.

Поставлена задача на 2017-2018гг. заменить все лампы уличного освещения на энергосберегающие.

В 2016году, в рамках подготовки к проведению 7-го Всероссийского сельского сабантуя, был произведен ремонт автодорог на общую сумму 26 млн.руб. Были заасфальтированы площадь в р.п. Старая Кулатка, центральные улицы с обустройством тротуаров и пешеходных переходов. Отремонтированы подъезды к центральной больнице и механико-технологическому колледжу.

Одним из значимых событий 2016г. по развитию клубных учреждений стало участие Новозимницкого сельского клуба имени Асанова в региональном конкурсе Народных инициатив. На средства областного, муниципального бюджетов и средства населения, спонсорские был проведен капитальный ремонт здания на 2,5 млн.руб.

В настоящее время, на конкурсный отбор поддержки народных инициатив, подан пакет документов на 7 объектов культуры, это Староатлашский, Старомостякский, Среднетерешанский, Стрarозелёновский сельские дома культуры, Вязовогайского, Бахтеевского сельских клубов и благоустройство Парка молодёжи. Общая сумма составляет 12,9 млн.

**Во 2 квартале планируем:**

1. Завершить строительство межпоселкового газопровода Старая Кулатка – Верхняя Терешка. Начать работы по проектированию строительства внутрипоселковых газопроводов в 5 селах (Новая Яндовка, Старая Яндовка, Средняя Терешка, Новая Терешка, Верхняя Терешка), а в 2018 году провести их газификацию. На проектирование необходимо порядка 29 млн. руб., включая экспертизу.

2. На 2017 год запланирован ремонт дорог объемом 31834 кв.м. сметной стоимостью 24,6 млн. руб. В 1 квартале составлены и утверждены сметы.

Будет проведен ремонт мостового перехода в с. Старое Зеленое,

Ремонт асфальтобетонного покрытия в с. Вязовый Гай ул. Чапаева и ул. Комсомольская (подъезд к дому Героя России Хабибуллина Р.М.),

Ремонт асфальтобетонного покрытия р.п. Старая Кулатка ул. Северная, Н. Северная, Красногвардейская, Молодежная.

Ремонт асфальтобетонного покрытия с. Новые Зимницы ул. Кузяхметова.

В р.п. Старая Кулатка реализуется инвестиционный проект ООО «Линостар» по производству бытового линолеума.

Объем производства линолеума за январь-декабрь 2016 года составил 163,7 тыс.кв.м (увеличение в 6,7 раза по сравнению с аналогичным периодом 2015 года - 24,4 тыс.кв.м). Объем реализации составил 14,7 млн. руб. (увеличение в 12,2 раз по сравнению с аналогичным периодом 2015 года – 1,2 млн. руб.).

В перспективе на 2017-2018 годы завод планирует увеличить производство линолеума до 85 тыс. кв.м. в месяц, что позволит создать новые высокопроизводительные рабочие места.

Для полноценной, бесперебойной работы завода необходимо строительство подъездной дороги протяженностью 1,2 км., т.к. дороги только грунтовые, что создает проблемы особенно в осенне - весенний периоды.

3. Для обеспечения бесперебойного водоснабжения будет проведен ремонт водопроводных сетей в с. Кармалей, стоимость работ 3,03 млн. руб. На сегодняшний день в муниципальном образовании «Старокулаткинский район» функции водоснабжения осуществляет ОГКП «Радищевский групповой водовод».

Проблемным остается вопрос реконструкции водопровода в р.п. Старая Кулатка по областной целевой программе «Чистая вода». Разработана ПСД по ремонту системы водоснабжения протяженностью 21 км общей сметной стоимостью 96 млн.рублей. После экспертизы получен положительный результат. До конца 2017г. планируется освоить 3,0 млн. руб.

4. Получение автобуса марки ГАЗ-322132. В связи с уменьшением количества обучающихся проведение мероприятий по закрытию основной школы в с. Верхняя Терешка, где сейчас обучаются 10 учащихся с 1 по 9 класс. С целью получения достойного образования детей из малокомплектных сельских школ планируется организовать подвоз учащихся из села Верхняя Терешка, где в настоящее время функционирует филиал Среднетерешанской СОШ Верхнетерешанская ООШ, в село Средняя Терешка. По школьному маршруту планируется проведение ремонта автодороги.

Требуется замена деревянных оконных блоков на пластиковые во всех образовательных организациях района.

5. Продолжить работы по благоустройству территории, реализовать проект обустройства парка Молодежи в р.п. Старая Кулатка путем устройства входа, установки ограждения, установки детских площадок. Создать и открыть в с. Вязовый Гай сквер им. Героя России Хабибуллина Р.М.

Для обеспечения учреждениями первичной медико – санитарной помощи в сельских поселениях необходим ремонт либо строительство модульных ФАПов, что остается проблемным вопросом на селе.

Проблемным вопросом остается отсутствие в ФОКа. В Старокулаткинском районе регулярно проводятся традиционные турниры, развиты популярные виды спорта такие, как легкая атлетика, настольный теннис, баскетбол, футбол, волейбол, хоккей. В целях поддержки и развития физической культуры и спорта необходимо строительство спортивного комплекса в р.п. Старая Кулатка.

Работа по исполнению наказов и предложений избирателей ведется планово, согласно «дорожной карте» и направлена на улучшение благосостояния населения, повышение комфортности проживания наших жителей.

Мы уверены, при поддержке Губернатора Ульяновской области С.И. Морозова и Правительства Ульяновской области, поставленные цели и задачи будут выполнены.

## Кыр эшләре киң колач ала



Иске Кулаткы районында язгы кыр эшләре көннән-көн киң колач ала бара. Бу вакытта хуҗалыкларның механизаторлары үләннәрне, туңга сөрү мәйданнарын, уҗым культураларын тырмалау һәм аларны тукландыру белән шөгыльләнәләр. Районыбызда 3124 гектар күпьеллык үләннәрнең 755 гектары, 18692 гектар туңга сөрелгән мәйданнарның 1045 гектары, 1483 гектар уҗым культураларының 80 гектары тырмаланды. Һава торышы уңай булганда, бу эшләр тагын да киң колач җәер әле.

"Латыпов Ф. Т." хуҗалыгында туңга сөрелгән мәйданнар һәм күпьеллык үләннәр тырмалау тәмамланды. Алар шушы көннәрдә язгы чәчүгә дә төшәчәкләр. Механизаторлар бу эшне алып барырга әзер торалар.

**Рөстәм АРИФУЛЛИН.**

## Араларны якын итеп



15 апрель көнне Тереньга эшчеләр бистәсенең мәдәни – ял итү үзәгендә, урындагы татар милли-мәдәни автономиясе бүлекчәсе тарафыннан, татар теле һәм мәдәнияте көне үткәрелде. Әлеге матур чараны оештыруда һәм Тереньга районында яшәүче татарлар белән элемтәне ныгытуда районыбыз Башлыгы Э. Ә. Ганеев зур тырышлык куйды. Аның инициативасы белән әлеге чарада безнең районыбызның мәдәният хезмәткәрләре, "Чишмә" ветераннар хоры коллективы зур тамаша күрсәттеләр. Артистларыбызның матур чыгышлары тамашачылар тарафыннан бик җылы кабул ителде һәм мактауга лаеклы булды. Ә инде районыбыз Башлыгы Э. Ә Ганеевның әлеге мөһим эшне алып баруы Тереньга район хакимияте һәм татар милли-мәдәни автономиясе тарафыннан югары бәяләнде һәм аңа истәлекле медаль һәм рәхмәт хаты тапшырылды.

**Актуальная тема**

## В Ульяновской области прошел II региональный форум «Фермерство - опора экономического развития сельских территорий».

**Андрей КОРЧАГИН**

На минувшей неделе в поселке Октябрьский, на базе Ульяновской государственной сельскохозяйственной академии, собралось более 300 человек - главы крестьянских фермерских хозяйств и сельские старосты, представители законодательной и исполнительной власти региона, эксперты научного и образовательного сообществ.

Посетил форум и губернатор Сергей Морозов.

- Поддержка агропромышленного комплекса была и остается одним из главных приоритетов правительства Ульяновской области, - заявил он. - В своем ежегодном Послании к Федеральному собранию РФ президент Владимир Путин поставил перед всеми задачу национального уровня - к 2020 году полностью обеспечить внутренний рынок отечественным продовольствием. Чтобы решить ее, мы должны сосредоточить ресурсы прежде всего на поддержке тех хозяйств, которые демонстрируют высокую эффективность. Мы не намерены снижать размер поддержки, предоставляемой нашим сельхозпроизводителям. В этом году на реализацию государственной программы по развитию сельского хозяйства в региональном бюджете заложено около 400 миллионов рублей. По итогам исполнения бюджета за I квартал будет выделено дополнительно 100 миллионов рублей на оказание финансовой поддержки аграриям для качественного и своевременного проведения весенне-полевых работ. Кроме того, мы изыскиваем еще 20 миллионов рублей на поддержку овощеводов.

Также губернатор напомнил о беспрецедентных мерах господдержки сельскохозяйственных потребкооперативов и о выделении 10 миллионов рублей на проект «Земский агроном».

- Его реализация задумана для привлечения кадров в сельские территории, - отметил Сергей Морозов. - Молодым специалистам, готовым переехать работать и жить в сельскую местность, региональная власть будет выплачивать по 1 миллиону рублей.

После этого губернатор вместе с исполняющим обязанности директора ООО «Агро-Нептун» Маратом Аббозовым подписали соглашение о реализации на территории Новоспасского района инвестиционного проекта. Согласно документу, в ближайшее время в селе Троицкий Сунгур будет построен животноводческий комплекс молочного направления на 1 200 голов.

В ходе пленарного заседания форума была затронута и тема тарифов на электроэнергию. О необходимости снизить затраты сельхозпроизводителей на этот ресурс высказался председатель Законодательного собрания Анатолий Бакаев.

- В Ульяновской области население платит за 1 кВт/ч чуть более 2 рублей, предприятия промышленности - от 3 до 4,5 рубля, а аграрии, входящие в группу «прочие потребители», - от 4 до 6 рублей и даже более, - напомнил спикер. - Эта проблема напрямую влияет на продовольственную безопасность, так как высокие энерготарифы повышают затраты сельхозпроизводителей и влияют на конечную цену продуктов питания. Тем самым снижается их конкурентоспособность по сравнению с импортными. А это недопустимо при реализации принципов импортозамещения. Очевидно, что возможность существенно снизить стоимость электроэнергии для АПК есть, и это должно осуществляться системно, в рамках государственной политики. Также есть возможность разработать различные виды субсидиарной поддержки АПК как на региональном, так и на федеральном уровне. Для этого необходимо направить в Правительство РФ предложения по изменению законодательства и найти способы ослабить тарифную нагрузку на агропром.

О развитии фермерского движения рассказал председатель ассоциации фермеров области Вячеслав Варганов.

- Приятно отметить, что, несмотря на санкции, сельское хозяйство развивается как в России, так и у нас, - заявил он. - По итогам прошлого года от экспорта зерна наша страна получила больше средств, чем от экспорта вооружений. И приятно отметить, что отличные достижения показывает фермерский сектор. Так, например, из 118 миллионов тонн зерна, собранных в прошлом году отечественными сельхозтоваропроизводителями, 33 миллиона - доля фермеров. Мы увеличили производство подсолнечника и сахарной свеклы, из года в год растет поголовье коров и производство молока. По темпам роста фермеры опережают другие секторы АПК. В целом малые формы хозяйствования производят 60% всего продовольствия в Российской Федерации.

Ассоциация фермеров Ульяновской области сегодня включает в себя 470 действующих фермеров, и о прогрессе их работы наглядно говорят цифры: в 2007 году они обрабатывали 106 тысяч гектаров земли, а в 2017-м - 245.

Затронул Варганов и «больные» моменты.

- Современная техника - это то, о чем болит душа фермера, - сказал он. - Государство, понимая важность этого вопроса, компенсирует часть затрат. В 2017 году на эти цели было выделено 13 миллиардов рублей. Но средства господдержки идут промышленным предприятиям, которые технику производят. При этом тракторы и комбайны дешевле не становятся. Считаю, что государство должно контролировать цену на сельхозтехнику.

По итогам форума была принята резолюция, в которую вошли ключевые задачи по развитию сельского хозяйства, повышению статуса институтов сельских старост и финансированию отрасли.



# О чём болит душа фермера

**КСТАТИ**

В рамках форума также прошла конференция ассоциации фермеров области и III региональный съезд сельских старост. Были организованы выставка-экспозиция сельскохозяйственной фермерской продукции и фотовыставка «Мое село».

## ТОСы в помощь

Опыт ТОС областного центра расширяется на сельские районы.

**Андрей КОРЧАГИН**

Ульяновская область - один из немногих регионов, опыт которых рекомендуют по всей России. Речь идет о движении ТОС, которое у нас получило развитие. Сегодня в регионе зарегистрировано 95 общественных организаций территориального общественного самоуправления (ТОС). Они объединяют около 130 тысяч человек, что составляет около 20% от населения области. А количество многоквартирных домов, входящих в ТОС, превысило 1000. Детсады, мосты, сельские клубы, спортплощадки - это далеко не полный список того, что создано руками участников территориального общественного самоуправления.

В целях дальнейшего развития и совершенствования системы в прошлом году по инициативе губернатора Сергея Морозова была создана ассоциация ТОС региона.



- Одна из главных наших задач - это популяризация движения ТОС, - заявил председатель ассоциации Владимир Сидоров. - Мы объясняем людям, что, создавая такие организации самоуправления, они становятся настоящими хозяевами своих домов, дворов и прилегающих территорий.

По итогам 2016 года региональной ассоциацией были заключены соглашения о сотрудничестве с городской думой Нижнего Новгорода, администрацией Арзамаса, МБУ «Контакт-центр» Ульяновска и Димитровграда, архитектурными учреждениями Ульяновска и области. В рамках этих соглашений будут сформированы социальные паспорта, содержащие все элементы благоустройства ТОС, намечен и согласован пятилетний план благоустройства, проведены просветительские семинары по вопросам создания и деятельности ТОСов в муниципальных образованиях Ульяновской области.

- Такие результаты достигнуты благодаря поддержке региональной власти, - считает Владимир Сидоров. - Ведь весь спектр мероприятий финансируется через муниципальную программу «Развитие территориального общественного самоуправления в муниципальном образовании «город Ульяновск» на 2015 - 2018 годы». Она включает в себя не только финансовую поддержку, но и организационную, консультационно-методическую работу.

Финансовая поддержка ТОСов осуществляется благодаря субсидиям. Среди ТОСов проводятся конкурсные отборы для организации и проведения на их территории мероприятий по благоустройству. Так, например, в 2016 году были определены 32 победителя, получившие субсидии на общую сумму около 3 миллионов рублей.

- К сожалению, пока движение ТОС в нашем регионе в основном развивается в Ульяновске, - констатирует Сидоров. - Но жители остальных муниципалитетов видят, как благодаря развитию ТОСов в последние годы преобразился наш региональный центр, стал более уютным и чистым. Как результат - в Димитровграде недавно были созданы первые четыре ТОСа, появились инициативные группы по их созданию практически во всех сельских муниципалитетах. В 2018 году планируется выделение 17,8 миллиона рублей на создание 115 новых ТОСов. Ведь если в каждом поселении будет хозяин, то везде будет порядок.

**«Ел символы булып травматизм һәм терәк-хәрәкәт аппараты авырулары профилактикасы буенча "Скандинавия йөреше" таяклары торырга тиеш. Әлеге спорт төре, җиңел булып күренүенә карамастан, травмаларны булдырмый калу уңаеннан организмны ныгытуда иң яхшы чараларның берсе булып тора. Йөреш вакытында мускулларның 90 проценты хәрәкәткә килә. Җәрәхәтләр алганнан соң тернәкләнүдә "Скандинавия йөреше" таяклары култык таякларына караганда яхшырак», - дип әйтәләр медицина белгечләре.**

**Бөек Ватан сугышының 75 еллыгына барганда**

# Әни сөйләргә кушмады



Бөек Ватан сугышы тарихында Ленинград блокадасы – иң аянычлы вакыйгаларның берсе. Шул ук вакытта бу совет халкының ныклыгын, фашист илбасарларын җиңүгә ышанычын да күрсәтте.

Ленинградның батыр халкы, 3 ел буена дошман чолганышында калып, ачлыкны, ялангачлыкны, ачы суыкларны үз җилкәләрендә кичерде, ләкин бирешмәде. Язмамның төп герое бу куркыныч көннәрне ишетеп түгел, үз күзләре белән күргән. Сүзем Ленинград блокадасын кичергән якташыбыз Иске Мостяк авылында яшәүче Расимә Сөләйман кызы Усманова турында.

– Сугыш башланганда, миңа бары 2 генә яшь иде. Абыем Камилга 4 яшь, ә сеңелем Сания 1942 елда туган. Әнием сөйләвенчә, без Ленинград өлкәсендә яшәгәнбез. Ул әтием белән пыяла ясау заводында хезмәт иткән. Сугыш башлангач, ике баласын һәм йөкле хатынын калдырып әтием фронтка киткән. Без ул чакта күргәннәрне, ул вакыттагы кичерешләрне мәңге онытасым юк. Төннәрен уянып, фаҗигале, авыр балачагым хакында уйланып йоклый алмыйча ятам.

Озак та тормый, 1942 елның сентябрендә, әтиебезнең Белоруссия җирендәге бәрелешләрдә һәлак булуы турында «кара» хәбәр килде. Әни, абый, мин һәм ике айлык сеңелем яклаучысыз калдык. Әниемнең сеңлесе Маһруй апа безне карашырга дип сугышка кадәр үк янызбызга килгән иде. Тик аңа унсигез яшь тулгач, фронтка алдылар. Ул чолганышка калып, әсирлеккә эләккән һәм аны Германиягә эшкә озатканнар, моны әнием сөйләвеннән беләм. Әнием, урыны оҗмахта булсын, бик сабыр, бик нык кеше иде, авырлыкны күп күрсә дә, 75 яшенә җиткәнче гомер итте. Аның: “Без бит ут астыннан чыктык, без күргәнне эт тә күрмәде,” – дип әйтә торган гадәте бар иде. Маһруй апабыз сугыш беткәч кайтты һәм авылдан китте.

Сталин приказы буенча әсирлеккә төшкән солдатларга дезертир итеп караулары һәм аларның гаиләләре сөргенгә җибәрелергә тиеш булулары турында кисәтелгән булган. Сталин: “Безнең хәрби әсирләребез юк, ватанга хыянәт итүчеләр генә бар”, - дип әйткән булган. Кыскасы, Сталин бу сүзләре белән әсирләрне бик тә авыр хәлгә куйган. Шулардан файдаланып, Гитлер безнең хәрби әсирләр белән ничек тели шулай кылынган. Шуңа күрә әниебез безгә моның турында авылга кайткач та беркемгә дә, беркайчан да сөйләмәскә боерык бирде. Хәтта безнең Ленинград өлкәсендә тууыбызны да яшереп туу таныклыкларыбызны алмаштыру җаен тапты. Әниемнең бер туган сеңлесе Маһирә апамның каенатасы да әсирлектә булып кайткан иде, аны атна саен НКВДчы чакыртып алып, баш иңенә наган тери булганнар. Ул: “...ат та үтер, инде хәзер мин кайтып гаиләмне күрдем, миңа үлем куркыныч түгел”, - дия булган.

Ул дәһшәтле елларда кечкенә булсам да, шунысын яхшы хәтерлим: бик салкын, бик куркыныч һәм бик караңгы иде. Таң беленү белән, көрәк тотып, әни окоп казырга, яисә безгә азык эзләп бакчалардан туңган бәрәңге казырга китә, ә без абыем, сеңелем белән бер-беребезгә сыенышып, көнозын өйдә утырабыз. Һава тревогасы ишетү белән күршеләр, әни шулай үтенгәч, безне дә үзләре белән бомбадан качу урынына алып китәләр иде. Әнием, шулай бер көн, көч хәлгә кайтып керде: “Янәшәбездә үк ядрә шартлады ди, җидәү үлделәр, без читтәрәк булганга исән калдык, сезнең бәхеткә дер инде, балалар”, - дип кочаклап җылады. Шундый авыр шартларда 900 шомлы көн һәм төн үткәрдек. Авызыбызга тәүлеккә бер тапкыр гына ризык эләгә, әни дөм караңгыда гына кайта. Безгә 150 грамм, үзенә 250 грамм ипи кисәге һәм бераз су алып кайта иде. Кыш көне бозны эретеп эчкән очраклар да аз булмады.

Шуларны искә төшерсәм, хәзер дә куркуымнан калтыранып китәм, – ди Расимә апа Һәм дәвам итә:

– Ленинград шәһәрен азат иткәннән соң да җиңел булмады. Безне әтиебезнең туган ягы - Иске Кулаткы районы Иске Мостяк авылына товар ташый торган поездга утыртып озаттылар. Без бик озак, бер - ике ай кайттык, чөнки кыска юл белән кайтып булмый, тимер юллар җимерек иде. Сугыш әле бетмәгән, әле монда шартлау ишетелә, әле тегендә бертуктаусыз ядрә ява. Без кайта торган поездга да бомба тиде. Андагы мәхшәрне сөйләп бетерә торган түгел. Шушы кайнар ноктада, шушы кышкы чатнама суыкта ничек исән калдык икән, дип хәйран калам. Кар-буран аша көч-хәл белән якындагы бер станциягә барып җиттек. Беркемдә кунарга кертми, әни Совет идарәсен табып мөрәҗәгать иткәч кенә, бер баракта урын таптылар. Шундый җәфа-газаплар белән арбалы- җәяүле туган авылыбызга кайтып төштек, безне колач җәеп әниемнең әти – әнисе, Маһирә апам каршы алдылар. һәр көн мунчалар ягып беттән, пычрактан арчыдылар. Торыр - сыенып урын булды, тик абыем, мин, әниебезгә ярдәм итеп балчыктан үз куышлыгыбызны булдырдык. Тик авылда да муллык түгел иде, әле бер күршедә, әле икенче кешедә булып, ачлы-туклы, иза чигеп халык белән бергә нужа арбасын тарттык. Әниебез авылга сыерлар фермасына эшкә урнашты. Сыер савучы апалар безне җәлләп, җылы сөт эчерә, кайчакта ипи дә алып килә иделәр.

Үсә барган саен без дә кул арага кереп, булыша башладык. Аннары мин сарыкчылык фермасында гомерем буе хезмәт иттем. Абыем Камил Сызран шәһәренә китеп урнашты, үз гаиләсен корып яшәде(хәзер мәрхүм инде), ә кече сеңелем Иске Кулаткыга кияүгә чыгып, бик матур гомер кичерде. Тик мин үземә пар эзләмәдем, әниемне ялгыз калдырып китәсем килмәде. Гомере буе икәү толлык арбасын тарттык. Дөрес, туганнарыма мең – мең рәхмәт, киявебезгә, абыема урыннары җәннәттә булса иде, гел булышып тордылар. "Дружба" колхозы ярдәменнән ташламады. Хәзер менә әниемнең сеңлесе Маһирә апам иң якын кешем, сердәшчем, җан юлдашым.

“Ә нигә блокада кичергәнегезне әйтмәдегез, документларыгызны эзләтмәдегез, льготаларыннан файдаланмадыгыз,”- дигән сорауларга “без исән калдык шунысы җиткән, дияр идем.. Әниебез: “... ул афәтне онытыгыз балалар, ул кабатланмасын, башкаларга күрергә Аллаһы Тәгалә язмасын, без күргәне дә җиткән” – дия иде. Хәзер мин дә шуны кабатлыйм, сугыш афәтләрен күрмәсәк иде, балаларыбыз, оныкларыбызны Ходай сакласын.

**Расимә УСМАНОВА.**
**Иске Мостяк авылы.**

**Дин, әхлак һәм вөҗдан ирегe**

# Канәгатьсезлек

***Йосыф Дәүләтшин вәгазьләре***

Аллаһ бәнләләрне бар итте, ризык бирде. Телләгән бәндәсенә ризыкны күбрәк, телләгән бәндәсенә ризыкны азрак бирде. Хәмед белән шөкер итәм, гөнаһымнан Аңа кайтам. Ул ялгызы, юк аның тиңдәш. Мөхәммәт – Аның илчесе. Салават шәрифләребез аңа булсын.

Кешелек дөньясы диннән ерагайган саен, җәмгыятебездә тискәре сыйфатлар артканнан арта бара. Аллаһы Тәгалә мул, чиста итеп биргән суларның балы бетә, корсаклар тулы булса да, ризыкның бәрәкәте бетә. Кешеләр арасында туган ризысызлык тамыр җәя. Карыннан үткән ризык та, оят җирләрен яшерүче кием дә, утыртып йөрүче ат та ул авыруны канәгатьләндерә алмый. Канәгатьсезлек, ризасызлык авыруы белән агуланган бәндә тотып карардай ризык белән туя алмый, киеп карардай кием белән канәгатьләнә алмый, утырып йөрердәй ат, машинадан канәгать була алмый. Ихтыяҗы үтәлә, машинасы да бар, йорты яңгыр-давылдан саклый, ләкин кешегә ул җитми. Ләкин күбрәк булса, яхшы булыр иде ди. Аллаһы Тәгаләгә шөкер итми, булганына шөкер итәргә кирәк дип үз-үзен вәгазьләми. Күп булса да, ул бәндәгә җитми. Нинди генә нигъмәтләре булса да, Аллаһ нинди генә мул тормыш бирсә дә, ул бәндәгә барыбер җитми, чөнки ул авырган бәндә, сәламәт бәндә түгел. Аның тәне сәламәттер, ләкин күңеле авыру. Шушы канәгатьсезлек авыруы белән чирләү сәбәпле, аңа күп булса да, җитми. Җитәр дип уйлаган халәтенә ирешә икән, аннары барыбер җитми икән. Менә болайрак кирәк икән! Ни өчен җитми? Чөнки авыру, аның күзе һаман да өскә таба карый, “Әлхәмдүлилләһ, каһчандыр ул нигъмәтем дә юк иде, хәзер бар”, - дими. Өскә карый да: “Кара. Ул миннән дә яхшырак”, - ди. Ялангач йөрми, киеме бар, “Аның киеме тагын да затлырак”, - ди. Аты бар, “Аның аты затлырак”, - дип, һаман өскә карый. Үзеннән түбән дәрәҗәдә, яманрак халәттә булучыларга күзен төшерә алмый. Табигатькә карасак, һәрбер нәрсәне төшерүгә караганда күтәрү авыррак. Күтәргәндә, җир тартып тора, шуңа күрә, күтәрү авыррак. Кулны күтәрү төшерүгә караганда авыррак. Ятактан тору авыррак. Күз байлык эзләсә, киресенчә, төшерергә авыр икән.

Яшь егет, урамда гаурәте күренгән хатын-кызны күрсә, күзен төшерә алмый. Канәгатьсез кеше дә күзен төшерә алмый. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: “Үзеңнән баеракларга карама, ә ярлыракларга карап, шөкер ит”. Ризасызлык белән авыручы үзеннән өстенрәкләрне карый. Аңа җитмәгәч, бервакытта да бәхетле була алмый. Кешенең 10 байлыгы булса да, барыбер үзеннән өстен кешене табар. Аллаһның гадел үлчәве дә бар. Әгәр дә кешенең бер нәрсәсе артса, икенче нәрсәсе төшә, нәрсәседер төшсә, икенче нәрсәсе күтәрелә. Бер яктан камиллеккә ирешсә, икенче яктан кимчелеккә төшә. Гыйлем алып, кемнеңдер иманы куәтләнергә мөмкин, ләкин сәүдәсе кимеп китәргә мөмкин. Кемнеңдер сәүдәсе артып, гыйбадәте кимергә мөмкин. Шуңа күрә, кеше бервакытта да төгәл камиллеккә ирешә алмый. Ризасызлык белән агуланган бәндә бер вакытта да үзе телләгән бәхеткә ирешә алмый, чөнки Аллаһ аңа бу хәлне бирми. Әгәр дә ризасызлык белән яшәгән кешегә шушы Җир шарының яртысын кисеп бирсәң, вәллаһи, ул беренче төнне үк йоклый алмаячак, чөнки икенче яртысы кемгә икән дип борчылачак. Бөтенесен бирәсең икән, Марс кемгә икән диячәк. Кояшта кемнәр бар икән диячәк. Адәм баласының канәгатьсезлек авыруы зур бер сынау. Бу чирдән дәваланырга кирәк. Аллаһның биргән нигъмәтләрен күрә белергә, алар өчен шөкер итәргә кирәк. Шул вакытта Аллаһы Тәгалә киемнең дә, ризыкның да бәрәкәтен бирер. Ризык калориясе күп булганга туйдырмый. Ризыкта бәрәкәт булса, тамак туя. Шуңа күрә, Хандак сугышында сәхабәләр пәйгамбәребез (с.г.в.) белән ач булганда, хәтта , ачлыкны аз гына булса да, басып торсын дип, корсакларына ташлар бәйләп куйдылар. Пәйгамбәребезнең күлмәге астында ике таш бәйләнгән иде, ул да сыналды. Бер сәхабә, пәйгамбәребезне кайгыртып. Өенә кайтып, бер бәрәнне чалдырды. Хатынына: “Әзерлә әле бәрәнне, хәзер Аллаһның илчесенә алып кайтып ашатыйк”, - диде. Кечкенә генә бәрәнне чалып, хәләл җефете шулпа пешерде. Бу сәхабә Пәйгамбәребез янына килеп, “Әй, Аллаһның илчесе”, - дип, колагына гына пышылтады. Сәхабәләр бик күп иде. Ә бәрән кечкенә булды. “Кечкенә генә ризык әзерләгән идек, әйдә, кайтып ризыклан”, - диде. Пәйгамбәребез (с.г.в.) чокыр эченнән чыкты да: “Кардәшебез безгә ризык әзерләгән. Әйдәгез, ашыйбыз”, - диде. Теге ризык әзерләүче сәхабә, хатыны янына кайтып болай диде: “Һәлак булдык, Аллаһның илчесе барлык сәхабәләр белән безгә кайта”. Чөнки ит шулкадәр кечкенә булса да, сәхабәләр бик күп һәм ач иделәр. Шул вакытта теге сәхабә әйтә: “Барлык сәхабәләр дә туйганчы ашадылар, соңыннан Аллаһ илчесе белән бергә утырып ашадык”. Аллаһ бәрәкәт бирә икән.

Әгәр күпме генә ризык булса да, Аллаһ бәрәкәт бирми икән, кеше шул ризыктан бәхет күрә алмаячак. Канәгать булу ул зур нигъмәт. Аллаһ аны кемгә бирде, шөкер итсен, шатлансын. Пәйгамбәребез (с.г.в.) дога кылды: “Әй Аллаһ, биргән ризыкларында миңа канәгатьлелек бирсәң иде”, - диде. Аллаһтан муллык кына түгел, канәгатьлелек тә сорарга кирәк. Җир өстендә иң канәгать кеше Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) булды. Зур-зур патшалар, кәрваннар белән алтынга күмелсәләр дә, ләкин пәйгамбәребез кебек арзый булып яшәмәделәр. Пәйгамбәребезнең берничә көн мичендә уты янмаса да, аның кебек канәгать кеше булмады. Пәйгамбәребез (с.г.в) әйтә: “Беркөнне Аллаһ Мәккә үзәнлекләрен алтынга тутырырга тәкъдим итте. Ләкин мин юк, кирәкмәс, Раббым дип әйттем. “Бер көн ач булыйм, бер көн тук булыйм. Әгәр тамагым ачса, Сине зикер итәрмен, әгәр тамагым тук булса, Сине шөкер итәрмен”. Әлхәмдүллилләһ, мөселман муллыкка ирешсә, Аллаһны мактый, сынаулар килсә, Аллаһны зикер итә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) тормыштан канәгать булып, Аллаһ биргән сынауларны гайрәт белән кабул итүчеләргә шатлыклы хәбәр әйтте: “Түбә агачы җәннәттә булыр кемгә? Кемнең тормышы җитәрлек кенә булып, ислам динендә булса. Очын-очка ялгап, тормышын алып баручы кешегә булыр”, - диде. Аның сәхабәләре нинди зур канәгатьлелек, ризалыкта яшәделәр. Аллаһка шөкер иттеләр. Бервакытта да үзләреннән байрак яшәүчеләргә карап көнләшмәделәр. Әбү ад-Дарда әйткән: “Байлар зур йортларда яшиләр, без дә урамда түгел, байлар затлы киемнәр кияләр, без дә ялангач түгел. Аларның, бездән аермалы буларак, артык маллары бар”. Байның 20 машинасы булса, ул бит егермесендә дә йөри алмый. 20 өе булса, берсе дә җитә бит, 20се кирәкмәс. Күпме ризыклары булса да, 5 мәртәбә артык ашый алмый. Шул байлар кирәк кадәресен генә кулланалар да, артыгына карап сокланалар. “Әгәр без дә теләсәк, барабыз да, аларның малларына карап сокланабыз”, - ди. Һәрберебез сокланса да. Артык маллар өчен без түгел, ә алар җавап бирәләр. Байның 3 катлы өенә карап, без дә сокланабыз. Ул да соклана, тик бөтен бүлмәләрендә дә яши алмас. Банктагы миллиардларга карап, ул да соклана, без дә сокланабыз.

Аллаһ Коръәндә әйтә: “Ир булса да, хатын-кыз булса да, кем Аллаһка иман китереп, изге гамәлләр кыла, аны яхшы тормыш белән яшәтербез”. Гали, Ибн Габбас дигән аятькә шундый тәфсир бирәләр: “Яхшы тормыш Аллаһ биргән канәгатьлелек булыр. Кемгә канәгатьлелек бирми, шул бәхетсез була”. Кем канәгать булды, аның тормышы яхшырыр, кем комсыз булды, аның ахмаклыгы артыр. Шуңа күрә, Раббым һәрберебезгә канәгатьлелек насыйп итсен. Бик күпләр авырый торган ризасызлык дигән авырулардан безгә шифа бирсен.

01 информирует

# Наступил пожароопасный период!

Сейчас весенне-летний пожароопасный период, а значит, опасность природных пожаров возростает в разы!

Пожароопасный период "весна - лето", скоро дачники откроют сезон. Количество пожаров и загораний в это время может возрасти в разы при сжигании прошлогоднего мусора и травы. Погода весной очень переменчива, и с усилением ветра во многих случаях даже небольшие очаги огня принимают большие размеры и зачастую приводят к тяжелым последствиям.

При ветре огонь молниеносно распространяется на соседние участки, что усложняет работу подразделений пожарной охраны. Поэтому сухой мусор нужно не сжигать, а вывозить в специально отведенные места. Ни в коем случае нельзя оставлять без присмотра костры.

Помните об ответственности за свои поступки: разведение костров, сжигание отходов и травы не разрешается ближе 50 метров от зданий и сооружений. Кроме того, территория вокруг участка для выжигания сухой травянистой растительности должна быть очищена в радиусе 25 - 30 метров от сухостойных деревьев, валежника, порубочных остатков, других горючих материалов и отделена противопожарной минерализованной полосой шириной не менее 1,4 метра, а лица, участвующие в выжигании сухой травянистой растительности, обеспечены первичными средствами пожаротушения.

**Частью 1 статьи 20.4 КоАП РФ установлена административная ответственность за нарушение требований пожарной безопасности:**

предупреждение или наложение административного штрафа на граждан в размере от одной тысячи до одной тысячи пятисот рублей; на должностных лиц - от шести тысяч до пятнадцати тысяч рублей; на юридических лиц - от ста пятидесяти тысяч до двухсот тысяч рублей.

Те же действия, совершенные в условиях особого противопожарного режима, -влекут наложение административного штрафа на граждан в размере от двух тысяч до четырех тысяч рублей; на должностных лиц - от пятнадцати тысяч до тридцати тысяч рублей; на юридических лиц - от четырехсот тысяч до пятисот тысяч рублей (часть 2 статьи 20.4 КоАП РФ).

В соответствии с указанием МЧС России от 17.02.2017 № 19-4-2-623, в рамках подготовки объектов и территорий к весенне-летнему пожароопасному периоду-2017 в Ульяновской области планируется совместно с органами местного самоуправления, полицией и МЧС патрулирование территорий в местах массового отдыха населения, населенных пунктов, садоводческих и дачных объединений граждан, летних оздоровительных лагерях, расположенных на территориях, прилегающих к лесам и подверженных угрозе перехода природных (лесных) пожаров.

Во всех населенных пунктах, подверженных угрозе лесных пожаров, планируется провести сходы граждан. А в случае необходимости на отдельных территориях будет введен особый противопожарный режим и ограничение на посещение гражданами и въезда автотранспорта в лесные массивы.

**Согласно ст. 8.32 КоАП РФ, нарушение правил пожарной безопасности в лесах в условиях особого противопожарного режима влечет наложение административного штрафа:**

на граждан – 4 000–5 000 рублей;

на должностных лиц – 20 000–40 000 рублей;

на юридических лиц – 300 000 - 500 000 рублей.

Для недопущения лесных пожаров органы местного самоуправления обязаны выполнить ряд мероприятий по созданию минерализованных полос шириной 5 м на всей протяженности участков границ населенных пунктов, очистить территории населенных пунктов от горючих отходов, мусора, сухой травы, а также обеспечить готовность к работе источников наружного противопожарного водоснабжения.

Напомню, с 1 марта 2017 г. вступило в силу Постановление Правительства России «О мерах по обеспечению пожарной безопасности в лесах», которое обязывает обеспечивать пожарную безопасность лесов, находящихся вблизи земельных участков.

Согласно документу, все собственники земельных участков обязаны очищать от горючих материалов полосу шириной не менее 10 м от границы леса либо создавать минерализованную полосу шириной не менее 10 м или другой противопожарный барьер. Это значит, что владельцам таких участков придется очищать сопредельную территорию от сухих веток, валежника и воспламеняющегося мусора либо оградить свою собственность неглубокой полосой по контуру леса шириной не менее 10 м.

Одна из основных причин лесных пожаров — неконтролируемое сжигание порубочных остатков (веток и валежника) лесозаготовителями. По правилам порубочные остатки должны утилизироваться на спецполигонах или сдаваться в переработку, на деле до 80% отходов сжигается на местах. Теперь компании, занимающиеся лесозаготовками, наряду с органами власти и местными жителями будут нести одинаковую ответственность за утилизацию горючих материалов на территории лесов.

Уважаемые жители Ульяновской области! В условиях сухой ветреной погоды возникает опасность природных пожаров. Будьте особенно внимательны при обращении с огнем! Не бросайте непотушенные сигареты на землю, сухая прошлогодняя трава и скопившийся за зиму мусор легко загораются. Также привести к пожару может бесконтрольное сжигание мусора.

**Напоминаю, в случае обнаружения очагов возгорания необходимо немедленно сообщить в пожарную охрану, набрав по мобильному телефону номера 101 или 112.**

**Игорь КИСИЛЕВ,**
**Начальник Главного управления МЧС России по Ульяновской области генерал-майор внутренней службы.**

**О внесении изменений в некоторые акты Правительства Российской Федерации по вопросу обеспечения пожарной безопасности территорий**

Правительство Российской Федерации

**постановляет:**

1. Утвердить прилагаемые изменения, которые вносятся в акты Правительства Российской Федерации по вопросу обеспечения пожарной безопасности территорий.

2. Настоящее постановление вступает в силу с 1 марта 2017 года.

Председатель Правительства
Российской Федерации
Д.Медведев

Изменения, которые вносятся в акты Правительства Российской Федерации по вопросу обеспечения пожарной безопасности территорий

**УТВЕРЖДЕНЫ**
постановлением Правительства
Российской Федерации
от 18 августа 2016 года N 807

1. Правила противопожарного режима в Российской Федерации, утвержденные постановлением Правительства Российской Федерации от 25 апреля 2012 года N 390 "О противопожарном режиме" (Собрание законодательства Российской Федерации, 2012, N 19, ст.2415; 2014, N 9, ст.906; N 26, ст.3577; 2015, N 11, ст.1607; 2016, N 15, ст.2105), дополнить пунктом 72_3 следующего содержания:

"72_3. В период со дня схода снежного покрова до установления устойчивой дождливой осенней погоды или образования снежного покрова органы государственной власти, органы местного самоуправления, учреждения, организации, иные юридические лица независимо от их организационно-правовых форм и форм собственности, крестьянские (фермерские) хозяйства, общественные объединения, индивидуальные предприниматели, должностные лица, граждане Российской Федерации, иностранные граждане, лица без гражданства, владеющие, пользующиеся и (или) распоряжающиеся территорией, прилегающей к лесу, обеспечивают ее очистку от сухой травянистой растительности, пожнивных остатков, валежника, порубочных остатков, мусора и других горючих материалов на полосе шириной не менее 10 метров от леса либо отделяют лес противопожарной минерализованной полосой шириной не менее 0,5 метра или иным противопожарным барьером.

2. Правила пожарной безопасности в лесах, утвержденные постановлением Правительства Российской Федерации от 30 июня 2007 года N 417 "Об утверждении Правил пожарной безопасности в лесах" (Собрание законодательства Российской Федерации, 2007, N 28, ст.3432; 2011, N 20, ст.2820; 2012, N 46, ст.6339), дополнить пунктом 9_1 следующего содержания:

"9_1. В период со дня схода снежного покрова до установления устойчивой дождливой осенней погоды или образования снежного покрова органы государственной власти, органы местного самоуправления, учреждения, организации, иные юридические лица независимо от их организационно-правовых форм и форм собственности, крестьянские (фермерские) хозяйства, общественные объединения, индивидуальные предприниматели, должностные лица, граждане Российской Федерации, иностранные граждане, лица без гражданства, владеющие, пользующиеся и (или) распоряжающиеся территорией, прилегающей к лесу, обеспечивают ее очистку от сухой травянистой растительности, пожнивных остатков, валежника, порубочных остатков, мусора и других горючих материалов на полосе шириной не менее 10 метров от леса либо отделяют лес противопожарной минерализованной полосой шириной не менее 0,5 метра или иным противопожарным барьером.

**ГКО УО "Старокулаткинское лесничество".**

# Департамент Министерства здравоохранения и социального развития Ульяновской области по Старокулаткинскому району информирует

с 1 декабря 2016 года вступило в силу постановление Правительства Российской Федерации от 19 ноября 2016 г. № 1221 «О внесении изменений в постановление Правительства Российской Федерации от 17 ноября 2010 г. №927» (далее-Постановление).

Целью Постановления является упрощение процедуры установления опеки близкими родственниками над лицами, страдающими психическими расстройствами и признанными в установленном порядке недееспособными по достижению ими совершеннолетия, при условии их постоянного совместного проживания не менее десяти лет к моменту подачи заявления о назначении опекуном.

К числу близких родственников отнесены родители, бабушки, дедушки, братья, сестры, дети и внуки.

Реализация данного Постановления позволит предоставить преференции близким родственникам и соответственно сократит время подготовки ими пакета документов, представляемых в органы опеки и попечительства.

В случае если близкий родственник, выразивший желание стать опекуном, не проживал с недееспособным гражданином в течение указанного времени, то оформление происходит в порядке, определенном пунктом 4 Правил подбора, учета и подготовки граждан, выразивших желание стать опекунами или попечителями совершеннолетних недееспособных или не полностью дееспособных граждан, утвержденных постановлением Правительства Российской Федерации от 17 ноября 2010г. №927.

Кроме того, Постановлением предусмотрено уменьшение числа проверок органами опеки деятельности опекунов-близких родственников до 1 раза в течение первого года после принятия органом опеки и попечительства решения о назначении опекуна или попечителя и 1 раз в 3 года в течение последующих лет.

Также, Постановлением предусмотрено упрощение формы отчетов опекунов и попечителей о хранении, об использовании имущества совершеннолетнего недееспособного или не полностью дееспособного гражданина и управлении этим имуществом в части исключения необходимости предоставления помесячных данных о величине доходов совершеннолетних недееспособных или не полностью дееспособных граждан.

В отношении опекунов - близких родственников Постановлением предусмотрено исключение представления информации о размерах пенсий, пособий и иных выплат совершеннолетних подопечных. По вопросу о расходах, включённых в категорию «прочих расходов», в отчетах, предоставляемых опекунами, сообщается, что данный вид расходов был предусмотрен в составе отчетов опекунов и до принятия постановления №1221. В связи с чем, указанным постановлением подходы к предоставлению отчетов в этой части не изменены. В категории «прочие расходы» указываются сведения о произведенных за счет средств подопечного расходах на питание, предметы первой необходимости и прочие мелкие бытовые нужды. Опекуны могут представлять отчеты в органы опеки как лично, так и посредством почтового отправления.

Данное постановление вступило в силу 1 декабря 2016 года и, соответственно, его действие распространяется на правоотношения, связанные с предоставлением отчетов опекунов, начиная с отчетов за 2016 год.

**Л.Ф. БЕКЕРОВА,**
**Главный специалист-эксперт Департамента Министерства здравоохранения, семьи и социального благополучия Ульяновской области по Старокулаткинскому району.**

Хуҗабикәләр игътибарына

# Помидор үстерү серләре

Бакча – күпләребез өчен тәҗрибә урыны да ул. Шуңа да без анда ел саен нинди дә булса яңадан-яңа үсемлекләр, яңа сортлар үстереп карарга омтылабыз. Бу помидорларга да кагыла. Соңгы дистә ел эчендә әллә никадәр яңа гибрид сортлар барлыкка килде, алар элеккеләреннән төрле чирләргә каршы торучанлыгы, салкынга чыдам булулары, югары уңыш бирергә сәләтле, хәтта декоратив булулары, һ.б. өстенлекле яклары белән аерылып тора. Моннан тыш, соңгы чорда помидорлар турында сүз чыкканда, безгә еш кына детерминант һәм индетерминант сортлар дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Бу ике сүз шуны аңлата: детерминант үсентеләр билгеле бер күләмдә ботаклар үстергәч, үзләренең үсешен тоткарлый һәм ачык туфракка утырту өчен файдаланыла. Индетерминант сортларда исә төп сабакның үсеше озак вакыт дәвам итә. Мондый сорт помидорлар югары уңыш бирергә сәләтле һәм аларны ябык грунтка утыртырга киңәш ителә.



Еш кына сатып алган орлыкларның күп өлеше «буш» була. Шуңа да, үсентесез калмас өчен, аларны башта тозлы суга салып карарга кирәгер. Моның өчен бүлмә температурасындагы 1 стакан суга 1 чәй кашыгы тоз салабыз һәм шуңа помидор орлыкларын салып болгатабаз. Стакан төбенә төшеп ятканнары утыртырга ярый дигәнне аңлата, өскә күтәрелгәннәрен исә алып ташларга киңәш ителә. Тозлы судан алгач, утыртасы орлыкларны чайкатырга онытмагыз.

Орлыкларны «Байкал-Эм1» препараты (башка махсус препаратлар да ярый) кушылган су салып юешләтелгән тукымада 10-12 сәгать дәвамында яткырганнан соң алдан әзерләп куелган тартмага (1 см тирәнлектә, араларын 2-3 см калдырып) туфракка чәчәбез. Тартманы якты һәм җылы урынга (20-23 градус җылылык таләп ителә) урнаштырабыз.

7-10 көннән соң беренче үсентеләр баш калкытыр. Алар 5-7 смга кадәр үскәч, помидор үсентеләрен яртылаш туфрак салынган 400 граммлы стаканнарга күчереп утыртабыз.

Үсеш барышында үсентеләргә аз-азлап туфрак өсти барабыз, кирәк икән, ян-яктагы яфракларын өзеп ташлыйбыз. Атнасына бер тапкыр сыек органик ашлама белән тукландырабыз.

Үсенте 30-40 см биеклеккә җиткәч, без аны, көчле тамыр системасы үстерү өчен, 1 литрлы савытларга күчереп утыртабыз. Әгәр сез үсентене май башларында ук теплицага утыртырга планлаштырасыз икән, соңгы операцияне башкарып тормасагыз да була.

**18 апрельдә илебездә Хәрби даны көне билгеләнде. 1242 елның 18 апрелендә князь Александр Невский җитәкчелегендә рус гаскәрләре, Чудской күлендә, немец гаскәрләрен җиңгән. Әлеге мөһим вакыйгаларны билгеләү уңаеннан район үзәгендә күркәм чара булып үтте.**

Хәтер уты сүнмәсен

# Камил Хабушевны искә алып

Апрель башында Кирюшкино авылының социаль - мәдәни һәм күңел ачу үзәгендә өстәл теннисы буенча 34 нче өлкә турниры үтте. Әлеге турнир Әфган сугышында батырларча һәлак булган Камил Хабушев истәлегенә багышланган иде.

Ярышларда Ульяновск, Сызран, Тольятти, Барыш шәһәрләре һәм Чардаклы, Чынлы, Кузоватово, Новоспасск, Николаевка, Радищево районнарының һәм төбәгебезнең спортчылары катнаштылар.

Ачу һәм бүләкләү тантанасында Иске Кулаткы район Башлыгы Э.Ә. Ганеев, район администрациясе Башлыгы И.А. Аблязов, район мәгариф идарәсе җитәкчесе Ф.З. Зайнетдинова, Терешка авыл поселениесе Башлыгы Р.Р. Тәминов, әфганчы-солдатлар Р.М. Байбиков, Ф.Б. Иксанов, Ф.З. Шабуров катнаштылар. Әлеге чараның олы кунагы - Камил Хабушевның әнисе Гөлҗиһан апа иде. Бу көнне аның адресына җылы сүзләр, ихлас теләкләр, олы рәхмәтләр күп яңгырады. Терешка авыл поселениесе исеменнән аңа истәлекле бүләк тапшырылды.

Чыгыш ясаучылар, өлкә турнирының яшь буынны тәрбияләүдә мөһимлеге турында ассызыкладылар һәм ярышта катнашучыларга уңышлар теләделәр. Ә инде Кирюшкино башлангыч мәктәбе укучылары мәктәп директоры Г.А. Рафикова җитәкчелегендә кунакларны сәламләделәр.

Судьялык эшен Р.Д. Мадьяров, И.А. Салихов, Р.К. Бикмаев алып бардылар.

Ярышларның нәтиҗәләре буенча командалар беренчелегендә Терешка авыл поселениесе командасы – беренче, Барыш шәһәре, Николаевка, Базарный Сызган районнары - икенче, Сызран шәһәре һәм Кирюшкино авылы командалары өченче урыннарга лаек булдылар.

Шәхси беренчелектә 14 яшькә кадәр егетләр арасында Данил Нәүмәтуллин (Бахтеевка авылы) – беренче, Илья Хурасев (әлеге авылдан) – икенче, Айрат Амиров (Кирюшкино авылы) һәм Дмитрий Яшкин (Николаевка районы) өченче урыннарга чыктылар.

Әлеге категориядә кызлар арасында Росита Бикмәтова (Кирюшкино авылы) - беренче, Юлия Абдуллина ( Кирюшкино авылы) - икенче, Марина Чичина (Николаевка районы) өченче урыннар яуладылар.

30 яшькә кадәрге яшьләр арасында Айрат Амиров (Сызран шәһәре) - беренче, Илья Сумбаев (Николаевка районы)- икенче, Эльнар Сәлимов һәм Раил Рафиков (Кирюшкино



авылы) иң осталары булдылар.

Әлеге категориядә кызлар арасында Ольга Чичина (Бахтеевка авылы), Сабина Будөлеева (Урта Терешка), Гуля Камалова һәм Ксения Поляева (Николаевка районы) иң яхшы нәтиҗәләр күрсәттеләр.

31 яшьтән өлкәнрәк хатын-кызлар арасында Иске Мостяктан Фәридә Зайнетдинова җиңү яулады. Ә инде ир-егетләр арасында Рәшит Адыгамов (Сызран шәһәре) - беренче, Марат Сәмерханов (Барыш районы) - икенче һәм Сергей Медведев (Сызран шәһәре), Илдар Тәминов (Кирюшкино авылы) өченче урыннарга ирештеләр.

Җиңүчеләр һәм призерларга Ульяновск өлкә физик культура һәм спорт Министрлыгының, район администрациясенең медальләре һәм Почет грамоталары, шулай ук Иске Кулаткы район Башлыгы Э.Ә. Ганеевның акчалата премияләре тапшырылды. Ул әлеге бәйгенең төп спонсоры иде.

Индивидуаль эшмәкәрләр Р.Р. Алиев, Р.Б. Ягудин, Р.Р. Ибраһимов, Ф.Р. Шарипов, Ю.В. Титова турнирны оештыруда һәм үткәрүдә зур ярдәм күрсәттеләр.

Бәйгедә “Иң кече катнашучы” буларак Гүзәл Сафина һәм “Иң өлкән катнашучы” буларак Фәрит Мохаммедов аерым бүләкләргә лаеклы иделәр.

Барлык спортчылар һәм кунаклар өчен мәктәп ашханәсендә туклandыру оештырылды.

Әлеге мөһим чара балаларны патриотик рухта тәрбияләү, физкультура-спорт эшен яхшырту һәм яшьләр арасында өстәл теннисын популярлаштыруга юнәлтелгән иде.

**Рөстәм АБУШАЕВ.**
**Кирюшкино авылы.**

Юмореска

## Партияләр төрле, тамак бер…

Эх, бу төрле партиялелек, биздерде бит дим үз алдыма. Шуның аркасында өйдә һәр көн ниндидер ыгы-зыгы килеп чыга да куя. Ник дисәгез? Мин Камил Кәримов әйтмешли үзем «Идинрус», хатын Зюганов партиясендә, балалар Жириновский яклы. Ә бер ерак туганым элек «Партия любителей пива» дигән партиягә кергән иде һәм урам буенда сыра эчеп үз сәясәтен яклап, каядыр суга ук сеңде.

Без - исән калганнар тырмашып-маташып дигәндәй яшәргә тырышабыз шулай. Дөньяга төрле карашларыбыз булса да, өйдә тәүлеккә өч мәртәбә аш бүлмәсендә, өстәл артында бергә күрешәбез. Тамак ул нинди генә партиядә булсаң да, ул үзе бер нәрсәгә генә — ашка табынып яши һәм аш турында уйлап аңа гына тугрылыклы булып кала.

Аллага шөкер, ризыкка мохтанганыбыз юк — төрле партияләрдә булсак та, йортта сыер да, сарыклар да, ат та бар һәм аларны төнлә чит яклардан караклар урлап китмәсеннәр диеп мылтык та сатып алдым (бу, билгеле, минем уяулыгым һәм тырышлыгым йогынтысы).

Мин өй һәм йорт хуҗасы буларак, үземә малларга азык табыштыру, хатынга сыер саву, балаларга атны һәм сарыкларны карау вазифалары билгеләдем. Тик алар тарафыннан бу вазифалар кайчан-кайчан үтәлеп бетми шул. Аш бүлмәсендә безнең карашлар бергә булса да, йортка чыккач, алар төрле якка таралып, пух-прахка килеп



юкка чыга.

Нинди генә хәлләр очраса да, мин йорт хуҗасы «Идинарус» буларак бу партияләрнең йогынтысына бирешмим һәм әби-бабамнан калган кәсеп — мал-туар үстерүне хуплап, аларны саклап калырга тырышамын.

...Менә шулай сәяси мөнәсәбәтләрне стабильләштереп, кыш та үтеп китте һәм бәрәңге утырту вакыты җитте.

Мин, гадәттәгечә, атны сукага җиктем һәм:

- Партияләр берләшегез, хәзер бәрәңге утыртабыз, мин «Идинарус» буларак сукадан тотам, син хатын Зюганов партиясе буларак ат башыннан тот, ә сез Жириновский партиясендәге балалар чиләкләрдәге орлыкларны буразнага салып йөрерсез, - дидем.

Аннан соң киләчәк буынның, киләчәк партиянең яшәвен кайгыртып:

- Чү! Чү! Оныкларны да компьютер артыннан торгызып, бакча өстенә чыгарыгыз, эшли белмәсәләр дә, карап торулары киләчәктә бердәм булып яшәр өчен дәрес булыр, - дип өстәп куйдым.

**Рөстәм АРИФУЛЛИН.**

2017 ЕЛ – Ульяновск өлкәсендә Мәрхәмәтле эшләр елы

# Гуманлы хезмәт ияләре

Кешеләрнең сәламәтлеген кайтару, аларга тормыш куанычларын бүләк итү кебек игелекле, чын мәгънәсендә - районыбыз ак халатлы белгечләре шунда дәваланып, үз аяклары белән чыгып киткән кешеләр газета аша гел рәхмәтләрен генә җиткереп торалар. Кабат – кабат язсаң да, аз кебек тоела. Чөнки алар үз - үзләрен аямыйча эшлиләр.

Мин үзем шикәр диабеты белән авыру, һәр ел Иске Кулаткы район больницасының терапия бүлегендә дәваланам. Быел участок табибыбыз Ф.З. Бахтиярова ирем, хезмәт ветераны, Маратны да дәваларга таләп итеп, больницага китерде, ирләр бит үз авыруларына игътибар бирмиләр. Аны кан басымы, йөрәк авыруы буенча дәвалауга салдылар. Терапия бүлеге табибы Р.Р. Азизова яшь кенә булуына карамастан, оста итеп эшне оештырды. Үзенең коллегалары: невролог А.Р. Кафизованы, Ә.Р. Масова-



ны, Л.Р. Сәләеваны чакыртып, киңәшеп дәвалау билгеләделәр. Сугыш һәм хезмәт ветераннары бүлмәсенә урын да бирделәр. Шәфкать туташлары: Галия Исмаилова, Илмира Хамзина, Гөлшат Мохамедова, Гөлсем Хәкимова, өлкән шәфкать туташлары Гөлсинә Курмашева белән Гөлсинә Сәләева табиблар билгеләгән процедураларны җиренә җиткереп үти бардылар. Һичкайчанда йөзләрен дә бозмыйча, безнең ыңыр – шыңырларга түзеп, күңелләрне тынычландырып кына тордылар. Мин аларга чын күңелемнән рәхмәт сүзләремне җиткерәсем килә, - ди Зирекле авылында гомер кичерүче Сания апа Забирова.

- Минем әниемне, Сания Азизованы, Яңа Терешка авылыннан бик авыр хәлдә Урта Терешка участок больницасының өлкән шәфкать туташы Фирүзә Фатих кызы Байкиева ярдәмендә китергәннәр, үз участок табибыбыз Л.Р. Сәләева аны больницага урнаштыруны оештырган, – дип сүзгә кушыла Сызран шәһәреннән әнисен карарга кайткан Римма Хаметова.

- Дәвалаучы табибы Регина Рафаэловна яшь булса да, квалификацияле табиб булуга охшаган, аның билгеләгән процедуралары белән әниемнең хәле ике – өч көндә уңайлана башлады. Алсу Ринатовна белән икәүләп барлык дәвалау процессын алып баралар. Кешегә мөнәсәбәтләре дә бик ошады, игътибарлы, ягымлы үзләре. Шәфкать туташлары турында югарыда сөйләгән барлык сүзләргә дә кушылам. Бик җитез һәм яхшы мөгаләмәдә медицина хезмәткәрләре. Ашатучы Фәридә апа Бадаева да, Гөлнара Кузәева да, хуҗабикә туташы Рәхилә Алтынбаева да, санитарка ханым да - барысы да пөхтәлек булдырырга, авыруларга уңайлыклар тудырырга тырышалар. Гомумән, коллективлары бик тату, бер – берсен ихтирам итү сизелә. Элеккеге медицина белән бүгенгесен чагыштырганда, аерма бик зур. Яшь табибларның районга кайтуы шатландыра, – дип сүзен тәгәлли Римма Хаметова.

Дөрестән дә, баш табиб С.А. Кунеевскиның да зур коллектив белән тиешле дәрәҗәдә эшне алып баруы сизелә. Аларга барчасына да олы рәхмәт сүзләре генә җиткерәсе килә. Безнең иң кадерле кешеләребезне саклап кала алганнары өчен без каршыларында баш иябез.

**Сания ЗАБИРОВА.**
**Зирекле авылы.**

# Ихтирамга лаек укытучыбыз



Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбенең укытучысы Гөлнәфис Юсуповна Шәмионова үзенең гомерен балаларга белем бирүгә багышлады. Ул күркәм холыклы, мактауга, ихтирамга лаек булган безнең балаларыбызның хөрмәтле укытучысы. Без, әтиәниләр дә, аның турында гел җылы сүзләр генә сөйлибез.

Гөлнәфис Юсуповна Иске Кулаткы урта мәктәбендә балаларга дөрес тәрбия биреп, һәр укучылары күңелендә туган телгә карата мәхәббәт уятуда зур тырышлык куеп хезмәт итә.

Ул укыткан II “Б” сыйныф укучылары үзләренең яраткан укытучылары белән гел канәгать булып белемнәрен үзләштерәләр. Укучылар арасында төрле бәйгеләр үткәрү дә - матур бер традициягә әйләнде.

Күптән түгел генә без дә, класс җитәкчебез Гөлнәфис Юсуповнаның инициативасы буенча үткәрелгән “Әниләр планетасы” дигән матур чарада катнаштык. Бу бәйрәм аеруча күңелләргә хуш килде. Матур итеп бизәлгән класста без үзебезне әкият дөньясында күк сиздек. Бу чарага апалары белән балаларыбыз да зур тырышлык куйганнар. Анда әниләр турында матур җырлар да җырланды, эчтәлекле шигырьләр дә сәнгатьле итеп сөйләнде. Укучылар үзләренең искиткеч чыгышлары белән әнигә карата мәхәббәт чагылдырып, безнең йөрәк түребезгә җылылык салдылар.

Әлеге бәйрәмдә балаларыбызның укытучысы Гөлнәфис Юсуповна үзе дә артистларча чыгыш ясады. Ул кыргыз шагыйре А. Токымбаеваның “Әни авырады” дигән шигырен сәнгатьле итеп укыды һәм без аның һәр сүзен зур канәгатьләнү белән тыңлап таң калдык. Мондый чаралар, билгеле, балаларыбызның уйлану сәләтен үстерергә, аларны күзәтүчән булырга, логик фикер йөртергә өйрәтә.

Ә инде 6 март көнне безнең балаларыбыз башлангыч сыйныф укучыларына һәм аларның класс җитәкчеләренә зур концерт программасы тәкъдим иттеләр һәм ул "Праздничное ассорти” дип исемләнгән иде. Аларның уңышлы чыгышлар ясавында да укытучыбызның йөзе чагылды.

Балаларыбызга тиешле тәрбия, тирән белем биргән өчен Гөлнәфис Юсуповнага рәхмәт сүзләребезне җиткерәсебез килә. Сезнең тырыш хезмәтегез нәтиҗәсендә балаларыбыз шулай ук төрле конкурсларда, олимпиадаларда катнашып, призлы урыннар яулыйлар (даими рәвештә Бөтенроссия, региональ һәм мәктәп конкурсларында бик актив катнашалар).

Мәктәбебезнең яхшы дәрәҗәдә булуы өчен мәктәп директорыбыз Гөлнара Вильдановна Бәшировага да рәхмәтебез чиксез.

Балаларыбызның теләп, яратып мәктәпкә йөрүләрен күреп без чын күңелдән сөенәбез.

**Барлык әти-әниләр исеменнән**
**Галия ХАБИЕВА.**

"Горячая линия"
21 апреля УПФР в Старокулаткинском районе пройдет «горячая линия» по вопросам апрельской индексации. На вопросы населения ответят специалисты с 13 до 16 часов. Ждем ваших звонков по телефону: 2-11-43; 2-11-64.

Гаилә кыйммәтләре

# Ярдәмчел һәм тырыш кешеләр



Кеше гомере сизелми дә үтеп китә икән. Ә инде халыкка файдалы эшләр башкарып яшәсәң, ул бер мизгел кебек кенә тоела. Яңа Терешка авылында ирле-хатынлы яшәүче Халидә Хөснетдиновна һәм Равил Таһирович Кузәевлар нәкъ шундый тойгыларга күмелеп, тыныч картлык көннәре кичерәләр. Аларны бу авылда белмәгән кеше юктыр, чөнки бу пар гомере буе тату яшәп, балалар үстереп, тырышып хезмәт итеп, авылдашларына тирә –күршеләренә гел ярдәм итеп тордылар.

Равил Таһирович элеккеге Иске Кулаткы район "Сельхозтехника"сының Урта Терешка МТМсында 43 ел токарь булып эшләде һәм шушы вакыт эчендә яшьләрнең остазы да булды. Аның белмәгән эше юктыр. Лаеклы ялга чыккач та, ул тынгылык белми авылның җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Моның турында мәчет картлары да, уртатерешкалылар да ачык итеп дәлиллиләр.

- Равил Таһирович үзенең вакыты белән кайчан да санашмый һәм дини йолаларыбызны башкаруда чын күңелен биреп катнаша, - дип сөйли Яңа Терешка авылының "Ишан" мәчете имамы Расим хәзрәт Аминов. Ул су буйлык авылның берәр өендә үле хәбәре ишетсә, авылдашларыбызның кайгыларын уртаклашып, һәр мәетне җирләүдә катнаша.

Аның тормыш иптәше Халидә Хөснетдиновна да шундый ук кешелеклелек сыйфатларына хас. Ул гомер агышында Урта Терешка авылының ваклап сату предприятиесендә хисапчы – кассир, кибетләрдә сатучы, икмәк пешерү цехында бригадир һәм Урта Терешка авылының тегү цехында тегүче булып хезмәт итте. Нинди генә участокта эшләсә дә, Халидә Хөснетдиновна һәр коллективта үрнәк булып торды.

Алар гомере буе пар күгәрчен кебек өй-йорт төзеп, мал-туар асрап, 50 елга якын тату яшиләр.

Бүген тыныч картлык көненә, балаларының тормышларына сокланып туя алмый бу гаилә. Кузәевларның балалары Роза һәм Ирек Майна районында, Кадрия - Урта Терешка авылында пар кошлар кебек үз ояларында яшиләр. Балалар да, оныклар да авылда еш булып, әти-әниләренең, әби-бабаларының хәлләрен даими белеп торалар. Халидә Хөснетдиновна һәм Равил Таһирович олы яшьтә булуларына карамастан, бүген дә йорт тулы мал-туар, кош-корт асрыйлар, бакча тулы яшелчә үстерәләр.

Менә шундый хезмәт сөюче, ярдәмчел, тормышны яратучы кешеләр булганда җәмгыятебездә яшәргә ансат һәм җиңел булыр иде.

**Рәхимә ШӘМИОНОВА,**
**"Терешка" авыл поселениесе администрациясенең белгече.**

2017 ел - Ульяновск өлкәсендә Мәрхәмәтле эшләр елы

# Әти, мин мөселман булдым

**Ир балаларны сөннәтле итү - шактый җаваплы эшләрдән санала. Табибка бардың да, операция ясатып кайттың түгел, моның өчен шактый физик һәм психологик яктан әзерләнергә кирәк. Азагының ни белән тәмамланасы да күңелне борчып тора.**

Без үзебезнең мөселманлыгыбызны исбатлар өчен, дин канунын үтәү максаты белән Иске Кулаткы район хастаханәсенә мөрәҗәгать иттек. Безне җылы итеп хирург - табиб С.В. Тюхматьев кабул итте. Ул безгә барысын да җентекләп аңлатты, тынычландырды.

"Сөннәткә утырту 20-40 минут дәвамында башкарыла, авыруны баса торган укол ясала. Пациент клиникада 1-3 сәгать дәвамында була, аннан өенә кайтарып җибәрелә. Әлеге операция катлаулы булмаса да, шактый борчулы процесс. Беренчедән, операция ясалыр алдыннан белгечкә тиешле анализлар белән килергә кирәк", диде.

Психологик яктан да ата- ана өчен борчулы хәл ул: савыгып бетәрме, операциядән соң өзлегүләр булмасмы? Чөнки сөннәткә утырткан баланы алып кайтканнан соң әле аны кимендә атна-ун көн сакларга кирәк. Җөйләр тәмам төзәлгәнче, аны бәрелүдән, егылу-сугылулардан саклап торырга кирәк булачак.

Хирургия бүлегенә барлык тиешле процедураларны үтәгәч, кертеп урнаштырдылар. Безне биредә ачык йөз белән шәфкать туташы Гөлсем апа Тимушева каршы алды, тынычландырды, барысын да аңлатты. Аннары анестезиолог – табиб Р.Р. Азизова кабул итте. Аның ягымлылыгы турында аеруча әйтәсе килә. Бигрәк игътибарлы, кешелекле үзе. Күңелебездәге шикләр, кайгыртулар юкка чыкты. Ә Алексей Масов үзенең җитезлеге белән күңелебезне җәлеп итте. Уколны да оста утыртты, калган процедураларын да җиренә җиткереп башкарды. Хирургия бүлеге санитаркасы Галия Рафиковага да рәхмәтебезне җиткерәсебез килә, тынычландырып кына баланы операция бүлмәсенә күтәреп алып кереп китте. Хирург - табиб әйткәнчә, озак та үтмәде улыбызны сөннәткә утыртып чыгардылар. Янәшәбездә тагын бер санитарка Гөлсем Сөнчәләева бала наркоздан чыкканчы караштырып, сөйләтеп торды, үзенең өч баласы, мондый хәлләр башыннан үткән, сабыр итәргә генә кирәк дип, күңелгә тынычлык салды. Гомумән, хирургия бүлегендә бик гуманлы, сабыр һәм тату коллектив эшли. Без гаиләбез исеменнән хирургия бүлегенең барлык хезмәткәрләренә чын күңелдән рәхмәт белдерәбез. Куллары һәрчак шундый шифалы булсын, күңелләре киң һәм иң мөһиме саулык – сәламәтлек үзләренә. Кешеләргә шатлык өләшүчеләр алар. Балабыз өйгә кайткач үк, йөреп китте, җөйләр тәмам төзәлде. Аллаһы Тәгалә йоласын җиренә – җиткереп башкарулары тагын да зур шатлык.

**ТУКТАРОВЛАР гаиләсе.**
**Яңа Мостяк авылы.**

# Битараф булмыйк!

Элек – электән хәйрия, янәшәдә яшәүчеләргә карата игътибарлы булу, кирәк вакытта ярдәм итү татар халкының күркәм гореф-гадәте булган. Ачлык ялангачлык елларында да, безнең әби-бабаларыбыз авылдашларына хәлләреннән килгән кадәр ярдәм күрсәтеп яшәгәннәр. Кызганычка каршы, соңгы вакытта битарафлык шаукымы тормышыбызга көннән-көн тирәнрәк үтеп керә бара. Көн саен диярлек тормыш төбенә төшеп калган райондашларыбызның фаҗигале рәвештә вафат булу хәбәрләрен ишетә башладык. Тик менә нишлисең, ул ялгызы гына яшәгән, эчүчелеккә бирелгән булган, - дип сөйлибез дә, онытабыз. Ә бит ул кешеләр безнең арабызда, янәшәбездә яшиләр. Күршебездә үк, эчүчелек белән мавыга башлаган яшьләрне белсәк тә, яшмибез, тиешле служба вәкилләренә хәбәр итәргә дә куркабыз. Болганчык заманда яшибез. Тирә-ягыбызны тәртипсезлек, әдәпсезлек, бозыклык, шәфкатьсезлек, битарафлык чолгап алган. Эчүчелек



көннән-көн киңрәк колач җәя. Исереклек афәтенә беркем дә битараф калырга тиеш түгел. Без XXI гасырда яшибез. Тормыштан артта калган кешеләр генә наркотиклар турында уйлыйлар. Без сәламәт яшәү рәвешенең киләчәктәге яктылык икәнен, бары сәламәт яшәү генә хыялларны тормышка ашырырга ярдәм иткәнен аңлыйбыз. Ә эчүчеләр, наркоманнар – алар үз көчләренә ышанмыйлар, аларның киләчәкләре юк. Безнең тирәбездә эчкечелек, наркомания, рухи пычраклык кебек куркыныч афәтләр йөри. Бу афәтләргә каршы торыр өчен барчабызга да аек акыл, сәламәт рух кирәк. Киләчәккә карыйк! Киләсе буынның язмышы өчен без җаваплы. Дөньяда бәхетсез булуга караганда, бәхетле булу җиңелрәк. Шуңа күрә якыннарыбызга, янәшәбездә яшәүчеләргә карата игътибарлы булыйк, тормышны яратып яшик. "Бар кеше изгелек кылса, яктырыр иде дөнья", - диелә мәкальдә. Әйе, игелек эшләүнең иртә киче юк. Башкаларның кайгысына битараф булмыйк һәм мохтаҗ кешеләргә кулдан килгәнчә ярдәм итәргә ашыксак иде!

**Гөлназ КУЗӘЕВА.**

К 100-летию революции 1917 года

# Кулаткинские татары о революции

«Государь затеял такую суматоху в народе…»

100-летие Великой Российской революции, которое отмечается в нынешнем году, заставляет нас задуматься над причинами и последствиями этого грандиозного социального катаклизма. В поисках причин произошедшего мы обращаемся к событиям начала XX века.

Нас в данном случае интересует то, что происходило в тогдашнем татарском обществе. Как вовлекались в общероссийское антимонархическое, революционное движение татары? Что вызывало их недовольство и пробуждало к протесту? Попытаемся ответить на эти вопросы на примерах из жизни наших земляков, кулаткинских татар. Приводимые ниже факты взяты нами из фондов Государственного архива Саратовской области.

В 1900г. Саратовским губернским жандармским управлением было заведено «Дело по обвинению крестьянина деревни Зимницы Хвалынского уезда М.С. Хасянова в оскорблении царя». По словам свидетеля, некого И.М. Окунева, Мубин Сейретдинович прилюдно обругал государя матными словами, добавив при этом: «Вот наш султан идет на вас! И тогда мы вас задавим!» Жандармы определили Хасянова «под особый надзор полиции».

Если до революции 1905 – 1907 годов среди татарского крестьянства случаи произношения оскорбительных слов в адрес носителя верховной власти были единичными, то в последующий период такие факты стали отмечаться регулярно. Это было связано как с тяжелым материальным положением основной массы сельского населения, так и с воздействием на него со стороны государственного пролетариата.

Ведь все больше молодых татар в поисках источников существования уходили на заработки в города, на шахты Донбасса, нефтепромыслы Баку и.т.д. Так, из призывников 1912 г. Деревень Старый Мостяк и Новый Мостяк на шахтах работали: Бульхин Махмут, Вяльшин Туктар, Насыров Ахтям, Мязитов Султан, Абдряхимов Мухамметалей и Хуснетдинов Айнетдин (последний приходится отцом автору этих строк. Хуснетдин Рашитов является моим отцом).

Антиправительственные настроения особенно усилились накануне и во время первой мировой войны. В донесении урядника помощнику начальника губернского жандармского управления по Вольскому, Хвалынскому и Кузнецкому уездам говорилось : «…запасной нижний чин из крестьян деревни Старой Кулатки Султан Зайнетдинович Юнусов, находясь 20 июня 1912г. в деревне Варваринке в пьяном виде, называл Государя Императора Николькой дураком и ругал его матерными словами». Весьма впечатляющим был перечень его претензий: «начальство все мошенники»; «царь целовальник, он не царь, только … винные лавки строит.»; «он, Никулька, нам земли не дает».

В самом начале мировой войны фигурантом жандармского дела стоял 70 летний житель деревни Старый Мостяк Гани Насыров. Случилось следующее. 23 августа 1914 года представитель общества Красного Креста Якуб Сунчалеев вместе со старостой Баки Хасяновым собирали по дворам пожертвования в помощь раненным воинам и их семьям. «Насыров, уклоняясь от жертвы»,-сказано в протоколе, - обругал особу его императорского величества скверноматерными словами и добавил: «Государь затеял такую суматоху в народе и начал грабить народ». Как видим полуграмотный крестьянин, верно определил грабительский характер только что начавшейся войны, ее ненужность простому народу. За «антиправительственные высказывания» Гани Насырова определили «под особый надзор полиции». Заметим, что от его имени идет известная мостякская фамилия Ганиевых. Его внук Исхак Хабибуллович в 1920-1930-е годы был видным советским работником в нашем районе. Нынешний глава Старокулаткинского района Эдуард Анварович Ганиев приходится Гани Насырову правнуком.

Персонажем еще одного политического дела стал житель деревни Новый Мостяк Искандер Исхакович Аксянов. Случилось это ближе к концу войны. Как явствует из донесения унтер-офицера Ивана Дергачева, явившийся 23 апреля 1916 года в Шиковское волостное управление 27 летний И. Аксянов отказался снять с головы шапку, а когда ему указали на висящий на стене помещения портрет императора Николая II, он заявил «Я сам император». В донесении имеется пояснение: «По мобилизации 1914 года принят в действующую армию, где был ранен пулей в правую руку, и в настоящее время около года проживает на родине». После проведенного в жандармском управлении дознания переписка о И.И. Аксянове была прекращена.

От себя добавлю, что Искандер Исхакович является отцом участника Великой Отечественной войны, вернувшегося в 1945 году домой с фронта без ноги, многолетнего заведующего Ново-Мостякской начальной школы, любимого и незабвенного учителя Мустафы Искандеровича Аксянова. Мустафа абый был настоящим коммунистом и советским патриотом.

Так через судьбы и переплетения судеб наших земляков проступает истинная суть Революции 1917 года как революции народной и освободительной.

**Ф.А.РАШИТОВ,**
**доктор исторических наук (г. Саратов).**

### БЕРГӘЛӘП УКЫЙБЫЗ

# КӨТЕП УЗГАН ГОМЕР

## Повесть

Зифа Кадырова




Лилия ашыга-ашыга машинадан төште, үзе розаларын кысып кочаклаган.

- Ник миннән көләсез, белеп торасыз, миңа өйләнә алмыйсыз.

Игорь да машинадан сикереп төште.

- Ник өйләнә алмыйм, кем әйтте?

- Чөнки мин сезгә тиң түгел, минем әтием дә әчкече, минем туганнарым да бар. Миңа өйләнү ул дүрт балалы хатын алу белән бер.

Игорь акрын гына килеп Лилиянең биленнән эләктереп алды.

- Беләсеңме, боланкаем, миңа менә шундый дүрт балалы хатын кирәк иде.

Алар бер мәлгә күзгә-күз терәшеп тордылар, Игорь кул астында яфрак кебек дерелдәгән тәнне тоеп, үзе дә дулкынлана башлады. Бу матур иреннәргә беркайчан беркем кагылмаган, алар аны гына көткән һәм алар аныкы. Аның иреннәренә кагылу белән ул эзләгән, аның өчен генә туган кыз бала икәнен тойды. Ул шашып-шашып, «бул минеке, тик минеке генә», дип пышылдады. Лилиянең тез буыннары тотмас булды, гомерендә дә бер кеше белән дә үбешкәне юк иде.

- Син ризамы минем белән бу тормышны бергә үтәргә?

Лилиягә бу төш, бу әкият булып тоелды.

- Моның булуы мөмкин түгел, - дип пышылдады, - бу төш бугай, - диде күзләрен ачмый гына, үзе аның куеныннан чыгарга көч тапмады. Игорь аны каз мамыгы кебек кенә итеп җирдән күтәреп алды.

- Мөмкин, әле ничек кенә мөмкин. Әйт, син ризамы Захарова булырга? Әйт, гүзәлем.

- Алдамасаң, риза.

- Әйдә, киттек безгә, әти көтә.

Александр Иванович аларны котлап:

- Балалар, тизрәк миңа бер кечкенә Раечка алып кайтып бирегез, - диде.

Лилия бу бәхеткә ышанып та бетә алмады, һавада очкан кош кебек хис итте үзен. Туй көне җиткәнче ышанмады, эштә дә белгертмәде. Бергә эшләгән кызлар арасында яшь хуҗага өмет итүчеләр юк түгел иде. Ике туйны бергә үткәрергә булдылар, җәй уртасына дип билгеләделәр. Игорьның туйга чаклы өстендә тагын бер зур бурыч тора иде, ул да булса Асылгәрәй калдырган хат.

«Мин өлгермәдем, син башкарып чык, шул кешене табып, әбиең белән очраштыр», диелгән иде хатта. Игорь инде ничә тапкыр хат язып карады, җавап килмәде. Инде үзе барырга җыенганда гына хәбәр килде, телефоннан сөйләшергә насыйп булды. «Сез кем, кемне эзлисез?» - диделәр вата-җимерә урыс телен.

- Сез килегез, килгәч аңлатырмын, сезне монда көтәләр.

- Ярый, билет алгач шалтыратырмын.

Туйга бер атна кала авылдан әбисе белән Мәхмүтне алып килделәр. Туйга әзерләнеп, өй эче гөрләп торды. Көтмәгәндә төн уртасында телефон шалтырады: «Мин Казанга килдем, кая барыйм?» Игорь сикереп торып киенә башлады: «Мин өч сәгатьтән килеп җитәм, шунда аэропортта гына утырып тор, хәзер киләм». Игорь төн уртасында бар көченә Казан юлы белән чапты. Үзе ничек аңлашасын кызалдына китерел, тегеләй әйтермен, болай аңлатырмын дип үзалдына кирәкле сүзләр эзләде. Ничек кабул итәр, ул бит олы кеше, ул бит аның бабасы. Игорь аэропортка килеп туктау белән залга йөгереп керде. Бермәлгә кемне эзләргә белми югалып калды. Ул карт булырга тиеш, ул ашыгып-ашыгып карт кеше эзләргә тотынды. Кемдер:

- Тукта-тукта, - дип артыннан килеп тотып алды. - Син мине эзләмисеңме? - Аның каршысында озын гына буйлы, какча гәүдәле, әле әллә ни карт булмаган адәм басып тора иде.

- Син Михманмы?

- Мин Михман.

Игорь елмаеп кулын сузды:

- Исәнмесез, әйдәгез тышка, машинада сөйләшербез.

- Мин һич аңламыйм: син кем улы, әтиең безнең авыл кешесеме?

Алар машинага чыгып утырып бераз киттеләр.

- Мин сезгә бернәрсә сөйлим, сез исегезгә төшерергә тырышыгыз. Моннан илле елга якын Михман исемле бер егет Урал тауларында хезмәт иткән, шунда Фатыйма исемле бер кыз белән очрашкан, хәтерлисеңме?

- Син Фатьманы каян беләсең? Мин Фатьманы бик яраттым, тагын сөйлә.

- Алайса, син Фатыйманы хәтерлисең. Менә шул Фатыйма Михманнан бала таба.

- Ничек бала таба, каян?

- Ул Михманнан ике бала таба.

- Тукта, туктат машинаны, ни сөйлисең, аңлатып сөйлә?!

- Сиңа Фатыйма әби аңлатып сөйләр, мин синең оныгын булам. Әби мине сиңа охшагансың, ди.

Михман машинадан төшеп кулларын белән башына ябышты, ул үз телендә нидер акрын гына такылдый-такылдый елый иде. Игорь аны килеп иңнәреннән кочаклады. Бабасы бик озак тынычлана алмады, авыр сулады:

- Кечер, балам, мин белмәдем, каһәр суксын бу тормышны.

Бабасы кабат-кабат күз яшьләрен сөртте.

- Ник соң син кире килмәдең? Әби сине гомер буена көткән, бүтән кияүгә дә чыкмаган.

- Кавказ законнары икенче шул. Мин кайтканда абыем чирләп үлгән иде, әти шуның тол калган, ике балалы хатынына өйләндерде. Бездә олыларга каршы барырга ярамый, бездә ата-анаң кемне сайлаган - шуңа өйләндерәләр. Мин үзем дә бик чирле кайттым. Бу армия минем бөтен гомеремне сындырды. Фатьма минем белән китмәде, ул балалар белән кайтса, әти мине башкага өйләндермәс иде. Минем ике балам туды, тик алар чирләшкә тудылар да үлделәр. Дүрт баладан берсе генә сәламәт калды, хәзер өйләнде, безнең белән яши. Ох, мин Фатьманы ничекләр сагына идем, аның янына качкан өчен генә мин биш ел җир астында үткәрдем.Ниләр генә күрмәдем, анда шартлау, анда үлем. Урал таулары искитмәле матур, тик аның җир астында бик куркыныч корал ясый торган заводлар да бар. Егерме биш ел беркемгә бернәрсә сөйләмәскә дигән кәгазьгә кул куйдырдылар. Күпме чир алып кайттым, кешегә сөйләп - аңлатып булмый, үзем дә һаман исән йөрүемә аптырыйм.

Алар таң атканчы диярлек юл буенда сөйләшеп утырдылар.

- Бабай, - диде Игорь Михман бабасының иңнәреннән кочаклап, - син бит минем бабам буласың. Минем әни, беләсеңме, нинди чибәр иде, кызганыч, күрешә алмадыгыз. Бабай, мин бит бүген өйләнәм.

Михман күз яшьләрен сөртеп оныгына карады.

- Мин бүген бәхетсез бәхетле. Фатьма, мин Фатьманы күрәсем килә. - Михман оныгын кочаклап күкрәгенә кысты - Улым, син үзең өчен дә, безнең өчен дә бәхетле булырга тиеш.

Алар таң алдында Чаллыга кайтып керделәр. Урман эче булганга, кошлар сайравыннан башка берни юк кебек, иртәнге тынлык. Алар капкадан кергәндә Игорь әбисенең ак яулыгын күреп калды, ул көндә иртән намазга тора да, бакчада йөри. Игорь бабасына:

- Син менә монда утырып тор, хәзер, - диде.

Фатыйма инәй бакчаны әйләнеп чыкты да, кайчандыр Рушаниясе яратып утыра торган урынга килде. Игорь аңа каршы торып басты да, бер читкә тайпылды: «Әби, утыр менә монда». Фатыйма инәй чит ир-ат янына утырырга читенсенеп, борылып китмәкче иде дә, теге кеше торып басты.

- Фатьма, Фатьма! - Михман аның кулларына үрелде, башын чайкый-чайкый әллә нинди сүзләр тезде. Фатыйма инәй баскан урынында катып калды.

- Михман, - диде аптырап, - син монда нишлисең?

Игорь аларның икесен дә кочаклап алды.

- Эх, картлар, утырыгыз, сөйләшегез. Әби, Алик абый сезне очраштырып өлгермәде, ул аны бик озак эзләгән, сезне бик тә кавыштырасы килгән.

Игорь аларның икесен генә калдырып китте, үзалдына бик бәхетле елмайды. Менә бит күпме туганнары булган, әнисе исән булса, дөнья түгәрәк булыр иде. Ах, әни, җитмисең шул син безгә! Игорь икенче каттан бабасы белән әбисенең сөйләшкәннәрен карап торды. Бабасы әбисенең кулларын үбә-үбә елый иде, әбисе дә авызын яулык чите белән каплап елый. Ничек аңлашырлар икән соң? Бер-берсенең телләрен дә юньләп белмиләр, хәер, әнә бит нидер сөйләшәләр.

Туйны үзләренең йортында гына үткәрергә булдылар, ресторанны да, ЗАГСны да шушында гына чакырдылар. Игорь кәләш алырга китте, аларда да туганнар җыелган. Тал чыбыгы кебек нечкә билле, ак күлмәктән басып торган Лилияне күргәч, кияү егете бар дөньяны яктыртып елмайды.

- Син очарга торган фәрештәгә охшагансың.

- Ә син мине алырга килгән бөркеткә, - дип, Лилия бәхетле елмаеп, булачак иренә сыенды.

Шаулап-гөрләп туйлар үтте. Игорь туй сәяхәте өчен Урал тауларын сайлады. Яллардан соң эшкә алар хатыны белән бергә килделәр. Күргәннәр пышылдаша башлады. Иртәнге планеркада һаман да ишек төбендә генә утырган хатынына карап елмайды да, аны җитәкләп өстәл башына - үзе янына утыртты.

-Таныш булыгыз, минем хатыным госпожа Захарова һәм минем урынбасарым.

Ул йөзекле бармагын күтәреп күрсәтте. Шундый тынлык урнашты - хәтта котларга да оныттылар. Халык офис коридорында да бик озак хушына килә алмады. Шушы кечкенә бер йолкыш чыпчык ничек шундый бөркетне үзенә өйләндерә алган? Юксаң, берсеннән-берсе чибәр аккошлар эшли монда.

Үзенең урынына әтисен калдырып сәяхәткә җыендылар. Әбисе белән бабасы бер минутка да аерылмадылар, Мәхмүт тә урталарыннан чыкмады. Бердән, уртада утыру рәхәт, икенчедән, әни белән генә картаеп килгән Мәхмүтнең әнисен берәү белән дә бүлешәсе килмәде. Михман Фатыйманың күзләренә карап гел авыр сулады. Җиңел түгел иде аңлашу да, аерылышу да. Өйдә гомер иткән хатыны көтә, уллары, оныклары. Ул монда килеп кабат Фатьмасын очраткач, кабат яшьлеккә кайткандай булды. Аларның йөрәкләре бергә булса да, һәркемнең үз юлы, үз тормышы булган. Михман да теләмәсә дә өйләнде, өйләнмим дип каршы килмәде, чөнки ата-бабадан калган гореф-гадәт: атаң әйткән икән, шул закон. Тормыш бара ул, үзенең көндәлек әйләнешен туктатмый. Тик аларның һәркайсының йөрәк түрендә беренче мәхәббәте яшәде. Хатыны беренче ирен уйласа, Михман Фатьмасын сагынды. Яшәделәр, балалар да ясадылар, чөнки шулай тиеш, ата-бабайлар шулай кушкан. Тик Урал тауларында очраткан мәхәббәт тә, башыңны югалтып шашып-шашып яратулар да бүтән кабатланмады. Барысы матур татлы төш булып кына калды. Хатыны белән кырык ел яшәп, яратасыңмы- яратмыйсыңмы дигән сүз дә булмады, талашмый-кырышмый яшәделәр дә яшәделәр. Чөнки шулай тиеш. Калган булса теге вакытта, бәлки башкача булыр иде. Кара, нинди матур кызы булган, кызганыч, үзе үстерә алмады, исән чакта күрешергә язмады. Ә оныклары нинди, берсеннән-берсе чибәр! Фатьма, сабыр Фатьма. Бер хатын җилкәсенә күпме сыеп. Күпме йөк, күпме югалтулар. Ник кирәк булган бу язмышка безне очраштыру? Йөрәкләр бер-берсен яратып типсәләр дә, бергә була алмагач. Бәхет өчен көрәшергә кирәк булгандыр да бит, әул кайтты да, шулай тиеш дип, бөтен йолаларга буйсынып яши бирде. Шым гына аның янына Мәхмүт килеп утырды, ул берсүзсез аңа текәлде. Михман да аңа карап алды. «Эх, Мәхмүт улым», дип аны кочаклап алды. Мәхмүт әтисе белән бер яшьтә күренә иде. Игорь эзләп тапмаган булса, бәлки алар бүтән беркайчан да очрашмаган булырлар иде, Михман да балалары барлыгын да белми үлеп китәр иде. Бүген ул бәхетле дә, бәхетсез дә иде.

- Бабай, барабызмы Уралга кунакка?

- Барабыз, улым.

Фатыйма элекке кебек хәерче яшәми иде. Аларны Айбулат гаиләсе белән каршы алды. Бөтен туганнар җыелып кабат бәйрәм иттеләр. Яшьләр туй сәяхәтенә - палаткалар алып Урал тауларына киттеләр. Фатыйма инәй һәм Михман Рушания белән Асылгәрәйнең зиратына килделәр. Михман каберләр алдына тезләнеп берсүзсез башын иеп утырды, янына чүгәләгән Фатыйма инәйнең каты итеп кулын кысты.

- Нинди матур балам булган, кем гаепле, ник бу язмыш безгә шундый мәрхәмәтсез булды соң?

Ул яшьле күзләрен Фатыймага күтәреп карады. Фатыйма инәй яулык очы белән генә битен каплаган, яшьле күзләр очраштылар, сүзсез генә бер-берсенә карап еладылар. Кайтканда Михман аны урман буена тартты.

- Хәтерлисеңме, торыйк-торыйк? Фатыйма инәй башын гына селкеде. - Фатьма, минем тормышымда бүтән торналар утравы булмады.

Фатыйма инәй дә кызарып, акрын гына:

- Минем дә, - диде.

Кунакларның китәр көне дә җитте. Михман Фатыймага карады да, авыр сулап ишекле-түрле йөрде, әле онытылып аның күзләренә карап торды. Фатыйма аның уйларын аңладымы:

- Утыр әле, - дип каршысына утыртты. - Син юкка өзгәләнәсең, буласы булган, гомер узган. Күрештек, сөйләштек, мин сине исән-имин тагын бер күрүемә бик шатмын. Яшьлек узган, безгә ни дә булса үзгәртергә соң инде. Мин сине гаепләмим, мин синең иләндә яши алмаган кебек, син дә монда яши алмас идең. Әнә балалар да туган илләренә кайтып башларын салдылар, үз илләрендә тынычлап йоклыйлар, аларны кайгыртырга монда мин бар. Сине дә үз иләндә көтәләр - хатының, балаларың. Мин үткәнгә үкенмим, үткән инде ул. Ходай шулай кушкандыр. Без синең белән хәзер зур бәйрәмнәрдә очраша алабыз. Оныкларның менә балалары туар, син кунакка килерсең, без тагын туйгачы сөйләшербез, безгә инде хәзер шул да җиткән.

Кунаклар китәр минутлар җиткәч, Фатыйма инәй Мәхмүткә:

- Без, улым, тәрәзәдән генә карап озатып калыйк, чыкма урамга, - диде.

- Юк, мин озатып калам. Ул кузгалып киткән машина артыннан йөгерде. Михман артына борылып карады, машина артыннан йөгергән улын күреп:

- Ай Аллам, тукта, балам йөгерә, - дип әзгәләнде.

Игорь машинаны туктатты. Михман төшеп улына каршы йөгерде, ул елыйелый улын күкрәгенә кысып-кысып сөйде.

- Мин озатам, мин озатам, - диде Мәхмүт.

Игорь бабасын көчкә машинага кертеп утыртты, авыр иде олы кешегә, әйтерсең, аның җаны икегә бүленде. Акылсыз булса да, ул аның баласы. Ул хәзер аның барлыгын белә торып, тагын Фатыймага калдырып китә. Мәхмүт элекке кебек олы юлга чаклы йөгерә алмады, карт иде шул инде, сирәкләр ул яшькә чаклы яши. Яшәсен иде шул әле, ансыз Фатыйма инәй нишләр? Үстергәндә балалар күп тә ул, янда һәрвакыт берәү генә кала. Акылсыз булса да, иптәш бит әле. Михман каерылып-каерылып артына карады, аның ярты җаны теге вакыттагы кебек Фатыймасы янында калды. Ник очраштырган соң аларны язмыш, гомер буена шулай сынар өченме?

Сыный язмыш кешеләрне, ирләрне-хатыннарны, хәтта бер гөнаһсыз сабый балаларны. Язмыш, дибез. Берәүләрне язмыш сыный, берәүләр үзләре язмышны. Бар идеме соң бу язмышларның башка юлы? Белмим, язмышларны Ходай кеше туганчы ук язып куя, диләр. Шулай булгач, бер ул гына белә бу бәндәләрнең язмышларын...

● РЕКЛАМАЛАР ● БЕЛДЕРҮЛӘР ● КАЙГЫ УРТАКЛАШУ ●

## ООО «Немецкие оконные изделия»



Рассрочка и скидки!!!

1. Заводское производство.
2. Гарантия качества.
3. Короткие сроки.
4. Установка входных и межкомнатных дверей.
5. Выезд на замер бесплатно.

При заказе 3 окон - жалюзи в подарок
При заказе 4 окон - дверь входная в подарок.
При заказе 5 окон - шестое окно в подарок.

*Условия акции по тел.: 89020040102; 89374588644; 89278018665.*

*Супер акция - окно из прорфиля 70 мм. по цене окна из профиля 58 мм.*

23 апреля
в Старокулаткинской районной больнице
с 8-00 ч. будет проводиться платный прием детей и взрослых,врачами УЗИ из г. Ульяновска. УЗИ брюшной полости (печень, желчный пузырь, поджелудочная железа, селезёнка)-1000 руб., УЗИ почек-700 руб., УЗИ гениталий (матка, яичники)-800 руб., УЗИ молочных желез-700 руб., УЗИ предстательной железы-700 руб., УЗИ мочевого пузыря-300 руб., УЗИ щитовидной железы-500 руб., УЗИ головного мозга-600 руб. В продаже имеются слуховые аппараты, батарейки, вкладыши. Цены от 4000 руб.
Справки по тел.: 8-937-27-27-27-0.

ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА
от производителя.
НАТЯЖНЫЕ ПОТОЛКИ НЕДОРОГО.
РАССРОЧКА.
Просто позвони.
Телефон: 89272125484.

21 апреля с 9.00 до 17.00 часов в РДК
Состоится ярмарка – распродажа конфет и чая из Казахстана, а также распродажа мужских футболок (200 – 400 руб.), женских футболок (200 – 300 руб.) и блузок (500 руб.), брюк и бриджей (550-650 руб.).
Ассортимент размера от 48 – 72.

Только 21 апреля в РДК
с 9.00 до 17.00 часов
состоится большая
РАСПРОДАЖА:
тюль-органза; вуаль; портьерная ткань от 100 руб. за метр, а также
покрывала, готовые шторы,
постельные комплекты.

Продаются: сруб пластин 6х8 м., мотоцикл «Урал», прицеп на мотоблок, автоген. Телефоны для справок: 2 – 20 – 06; 89297906282.

Магазин «Миндаль» проводит весеннюю акцию продаж:
картофель промышленный - 21 руб. за 1 кг.;
семенной – 11 руб. за 1кг.;
сахар-песок – 37ру.90 коп. за 1 кг.;сечка-гречневая 19 руб.90 коп за 1 кг.; большой ассортимент кормов с биодобавками для животных и птиц.
Цены действительны на день публикации. Спешите, количество товара ограничено.
С 18.04.2017г. магазин по адресу: М. Джалиля, 14 А меняет режим работы с 7.30 до 22.00 часов. Адреса магазинов: ул. М. Джалиля, 14 А, ул. Метро, 112. Справки по телефонам: 2 – 30 – 35; 8- 927 – 815- 3000; 8 – 927 – 802 – 03 – 03.

Район сугыш һәм хезмәт ветераннары Советы, Иске Зеленайдан хезмәт ветераны **Аҗирә Таһировна КУДЯЕВАНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, якыннарының, туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.

Район сугыш һәм хезмәт ветераннары Советы, Иске Кулаткыдан хезмәт ветераны **Рушан Зәкәрьевич БИМЕЕВНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, якыннарының, туганнарының тирән кайгысын уртаклашалар.

МУП "Благоустройство" оешмасы коллективы хезмәткәр **Рушан Зәкәрьевич БИМЕЕВНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, тормыш иптәшенең, балаларының, оныкларының тирән кайгыларын уртаклаша.

## ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА

Производство и установка пластиковых окон.

При заказе пяти окон, шестое – бесплатно!
Замер, доставка – бесплатно.

*Наше качество и доступные цены порадуют вас! Пенсионерам – дополнительная скидка!*

20% скидка



Телефон: 8-937-278-05-55.
Павловка.



- Окна от производителя
- \+ комплектующие
- Двери «Бульдорс»
- Натяжные потолки (от 240 руб./в.м)

Телефоны: 88422(651832), 89041823507, 89374550649.




Натяжные потолки
«Җиде һава»
Недорого.
☎ 89021273125.

## Стоматология ООО «Дента Люкс»



приглашает вас воспользоваться качественными услугами современной стоматологии
пациентам нуждающимися в протезировании готовы предложить:
- съемное протезирование: протезы из акриловых пластмасс, бюгельные, нейлоновые;
- несъемное протезирование: коронки с покрытием, металлокерамические, комбинированные, цельнолитые и.т.д.

Запись предварительно по тел.: 89278033404, Пионерская, 18 А. Консультация бесплатно.

Безнең өчен кадерле, сөекле кешебез - тормыш иптәшем, әниебез **Кәүсәрия Зәйдулловна АХТӘМОВАНЫ** хөрмәтләп, соңгы юлга озатуда катнашкан, ярдәмләшкән, кайгыбызны уртаклашкан өчен "Җәмигъ» мәчете имамы Рафаэль Ахмеровка, «Әнвәр» мәчете мәхәлләсе картларына, төн кунучы әбиләргә, барлык туганнарга, дусларга, тирә-күршеләргә: Киряшиннарга, Абдельмәновларга, Аблязовларга, Юмаевларга, Ахметовларга, Юнусовларга, Хәбибуллиннарга, якын күреп килүче халыкка олы рәхмәтебезне белдерәбез. Ходай Тәгалә беркемгә дә кайгы-хәсрәт күрсәтмәсен.
**Ахтәмовлар, Юнусовлар гаиләләре.**
Иске Кулаткы – Казан – Ульяновск.

Район сугыш һәм хезмәт ветераннары Советы, Усть Кулаткыдан хезмәт ветераны **Али Мөҗипович ИКСАНОВНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, якыннарының, туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.

Район сугыш һәм хезмәт ветераннары Советы, Бахтеевкадан Бөек ватан сугышы ветеранының тол хатыны, хезмәт ветераны **Файлә Хәйдәровна АМИНОВАНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, якыннарының, туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.

Район сугыш һәм хезмәт ветераннары Советы, Иске Кулаткыдан сугыш елы баласы **Әмерхан Юнесович УСМАНОВНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, якыннарының, туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.

Безнең өчен кадерле кешебез, тормыш иптәшем, әтиебез, бабакаебыз, кодабыз **Әмерхан Юнесович УСМАНОВНЫ** хөрмәтләп, соңгы юлга озатуда катнашкан, ярдәмләшкән, кайгыбызны уртаклашкан өчен «Гани» мәчете имамы Рәхимҗан хәзрәт Фәйзуллинга, мәхәллә картларына һәм абыстайларга, төн кунучы әбиләргә, Иске Кулаткы икенче номерлы урта мәктәбе коллективына, барлык туганнарга, тирә-күршеләргә, дус-ишләргә, Хвалынск, Саранск шәһәрләреннән килгән туганнарыбызга, Усмановлар, Арслановлар, Кузәевлар, Тимербулатовлар, Ереминнар, Рафиковлар, Мәгдиевлар, Рәхмәтуллиннар гаиләләренә, якын күреп килүче халыкка олы рәхмәтебезне белдерәбез. Ходай Тәгалә беркемгә дә кайгы-хәсрәт күрсәтмәсен.
**Усмановлар, Зөлкәрнәевлар гаиләләре.**
Иске Кулаткы –Казан.

"Хвалынский горнолыжный курорт" реализует подрощенных и суточных цыплят - бройлеров КОББ 500. Телефон: 89276267339.

Продаются дрова. Цена договорная. Телефон: 89084870405.

Продаем гаражи металлические (пеналы) новые и б/у. Размеры любые. Доставка бесплатная. Цена от 26 тыс. руб. Тел.: 89063969864; 88007009091.

В р.п. Радищево ИП «Рамаев Д.А.» принимает заявки на суточных и подрощенных бройлеров, индюшат, гусят, утят и мулардов на март, апрель и май. Телефоны: 89278035043, 884239 22-6-16.

В селе Усть Кулатка продаются пчелосемьи. Обращаться по телефонам: 35 – 2 – 81 (после 18.00 ч.), 89278146557.

В с. Бахтеевка продается трактор «Т-40» в рабочем состоянии, без документов. Цена 45 тыс.руб. Телефон: 89276123116.

Продаются овцы и дрова. Телефон : +79041914789.

В р.п. Старая Кулатка продвется бревенчатый дом площадью 70 кв.м., с земельным участком – 1200кв.м., частично с мебелью. Со всеми удобствами и ремонтом+ евроокна, двери. Имеются: баня, гараж, сараи, погреб. Недалеко детский сад и школа №1.Рассмотрим варианты обмена (с доплатой) на квартиру в районе ул. М. Джалиля. Возможно приобретение на жилищные сертификаты. Недорого. Цена договорная. Телефон: 8 – 927 – 986 - 62 – 55.

Мәгариф хезмәткәрләренең профсоюз оешмасы һәм "Чишмә" балалар бакчасы коллективы элеккеге медицина хезмәткәре **Халидә Фәйзрахмановна АВВЯСОВАНЫҢ** вафат булуын белдерәләр һәм гаиләсенең, туганнарының тирән кайгысын уртаклашалар.

Иске Кулаткы район больницасы коллективы сәламәтлек саклау тармагында озак еллар намуслы эшләгән шәфкать туташы **Халидә Фәйзрахмановна АВВЯСОВАНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, якыннарының, туганнарының тирән кайгысын уртаклашалар.

Безнең өчен иң кадерле, иң якын кешебез, яраткан әниебез, әбекәебез, апабыз **Сәгадәт Хәсәновна АМИРОВАНЫ** хөрмәтләп, соңгы юлга озатуда катнашкан, ярдәмләшкән, кайгыбызны уртаклашкан өчен Иске Кулаткы сәнгать мәктәбе коллективына чын күңелдән олы рәхмәтебезне белдерәбез.
**Амировлар, Шамуковлар, Үмәровлар гаиләләре.**
Яңа Кулаткы – Усть Кулаткы - Ульяновск.

Район сугыш һәм хезмәт ветераннары Советы, Яңа Кулаткыдан Бөек ватан сугышы ветеранының тол хатыны, сугыш елы баласы, хезмәт ветераны **Сәгадәт Хәсәновна АМИРОВАНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, якыннарының, туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.

Район сугыш һәм хезмәт ветераннары Советы, Иске Зеленайдан икенче группа инвалиды **Рәфәгать Вильданович СӘЙФЕТДИНОВНЫҢ** вафат булуы сәбәпле, якыннарының, туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.

Директор-баш редактор
М.С. МАСИЕВА.

Адрес редакции, издателя:
433940
р.п. Старая Кулатка
Ульяновской области,
ул. Куйбышева, 22.
ОАУ Редакция газеты
"Кумяк кюч".

Телефоннар:
электрон адрес:
kumiakk@mail.ru
884(249)2-11-94-редактор, факс, бухгалтерия;
884(249)2-12-64 - журналистлар, реклама бүлеге, РИК операторлары.

Индекс 54505.
Газетаны басарга кул кую вакыты:
график буенча - 16.00
фактта - 16.00
Тираж 2800
Заказ № 13/16
Распространяется по подписке.

Газета отпечатана с готового оригинала-макета
в ООО «Принт Хаус»
432071, г. Ульяновск, ул. Федерации, 15.

Элемтә һәм масса - күләм коммуникацияләр сферасында күзәтү буенча Федераль службаның Ульяновск өлкә идарәсе 2014 елның 21 ноябрендә ПИ №ТУ73-00388 номерлы масса-күләм информация чарасын регистрацияләү таныклыгы белән регистрацияләнде.
Газета битләренә урнаштырылган рекламалар һәм белдерүләр өчен редакция җаваплылык тотмый.
Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
Хатлар, кульязмалар һәм рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.